# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы референдумы турында**

Татарстан Республикасы референдумда гражданнарның иркле ихтыяр белдерүен, Татарстан Республикасы референдумында катнашу хокукының демократик принципларын һәм нормаларын яклауны гарантияли.

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Әлеге Законның гамәлдә булу чикләре

1. Әлеге Закон даими яисә күбесенчә Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба – гражданнарның) Татарстан Республикасы референдумында катнашуга Россия Федерациясе Конституциясендә, Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган конституциячел хокукын гамәлгә ашыруның төп гарантияләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы референдумын билгеләү, әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының бүтән законнары белән җайга салына.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасы референдумы

1. Татарстан Республикасы референдумы (алга таба – референдум) иркле сайлаулар белән бергә халык хакимиятенең иң югары турыдан-туры

257

чагылышы булып тора. Референдум гражданнарның дәүләт әһәмиятенә ия мөһим мәсьәләләр буенча тавыш бирүе ул.

2.Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үткәрелә.

3 статья. Референдум үткәрү принциплары

1. Граждан референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән катнаша.

2. Гражданның референдумда катнашуы ирекле һәм ихтыярый. Гражданны референдумда катнашырга яисә катнашмаска мәҗбүр итү максатында, шулай ук аның ирекле ихтыяр белдерүенә йогынты ясарга беркемнең дә хокукы юк.

3. Референдумны әзерләгәндә һәм үткәргәндә, тавышларны санаганда һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә, референдум нәтиҗәләрен ачыклаганда референдум комиссияләре эшчәнлеге ачык һәм хәбәрдар гамәлгә ашырыла.

4 статья. Референдумда катнашу хокукы

1. 18 яшькә җиткән граждан референдумда тавыш бирү, референдумга әзерлек буенча законда каралган һәм законлы ысуллар белән үткәрелә торган башка гамәлләрдә катнашырга хокуклы.

2. Граждан референдумда җенесенә, нинди расадан булуына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, иҗтимагый берләшмәләрдә торуларына, шулай ук башка хәлләргә карамастан катнаша ала.

3. Суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип танылган яисә суд карары буенча ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылучы гражданнар федераль закон нигезендә референдумда катнашу хокукына ия булмый.

5 статья. Референдумда катнашуга тигез хокук

Гражданнар референдумда бертигез нигезләрдә катнашалар.

258

<u>6 статья.</u> Референдумда турыдан-туры ихтыяр белдерү хокукы

Референдумда граждан референдумга чыгарылган сорауны хуплап яисә аңа каршы турыдан-туры тавыш бирә.

<u>7 статья.</u> Яшерен тавыш бирү

Референдумда тавыш бирү яшерен була, гражданның ихтыяр белдерүен теләсә ничек тикшереп тору мөмкинлегенә юл куелмый.

<u>8 статья.</u> Референдум үткәрүнең теле

Референдумга чыгарыла торган закон проектларының текстлары һәм карар проектлары тавыш бирү бюллетеньнәре, референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәләр һәм белешмәләр, референдумда кабул ителгән карарлар, дәүләт хакимияте органнарының референдум үткәрүгә кагылышлы документлары Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, кирәк очракларда халык күпләп яши торган территориядә файдаланыла торган телләрдә төзелә (басылып чыга).

## II бүлек. Референдум үткәрү инициативасын гамәлгә ашыру, референдумны билгеләү

<u>9 статья.</u> Референдумнар үткәрү мәҗбүрилеге

1. Референдум әлеге Законда күрсәтелгән тәртиптә һәм вакытларда билгеләнә һәм үткәрелә. Референдумны билгеләү турындагы карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы тарафыннан референдумга чыгарылырга мөмкин булган мәсьәләнең асылы буенча карар кабул ителү әлеге сорау буенча референдум үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәп булып тормый.

10 статья. Референдум мәсьәләләре

1. Референдумга Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр (моңа Россия Федерциясе Конституциясе, федераль конституциячел закон, федераль закон белән җайга салынган мәсьәлә очрагы керми) чыгарылырга мөмкин.

2. Референдумга түбәндәге мәсьәләләр чыгарыла алмый:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә озайту, вәкаләтләр башкаруны туктатып тору, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары сайлауларын вакытыннан алда үткәрү яки мондый сайлауларны кичектереп тору турындагы;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары составын, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының шәхси составын формалаштыру турындагы;

в) депутатларны, урындагы затларны сайлау, раслау, билгеләп кую хакында йә вазыйфаларына билгеләп куюга яисә вазыйфаларыннан азат итүгә ризалык бирү турында;

г) Татарстан Республикасының Республика бюджетын кабул итү яисә үзгәртү турында, Татарстан Республикасының финанс йөкләмәләрен үтәү һәм үзгәртү хакында;

д) халыкның сәламәтлеген һәм иминлеген тәэмин итү буенча гадәттән тыш һәм ашыгыч чаралар күрү турында.

3. Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр референдумга чыгарыла алмый.

4. Референдумга чыгарыла торган мәсьәләләр кеше һәм гражданның гомумтанылган хокукларын һәм ирекләрен, андый хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыруның конституциячел гарантияләрен чикләргә яисә кире кагарга тиеш түгел.

5. Сораулар төрлечә аңлату мөмкинлеге калмаслык итеп төзелергә тиеш.

6. Референдумга чыгарылучы сораулар аларга бертөрле генә җавап бирә алырлык итеп төзелергә тиеш.

7. Референдумга чыгарылучы сораулар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел.

11 статья. Референдум үткәрү мөмкин булмаган очраклар

1. Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы территориясендә йә Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә кертелгән хәрби яисә гадәттән тыш хәл шартларында, шулай ук хәрби яисә гадәттән тыш хәл беткәннән соң өч ай дәвамында референдум үткәрелми.

2. Референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккач (халыкка җиткерелгән) көннән соң ике ел дәвамында мәгънәсе ягыннан шундый ук төзелгән сорау буенча яңадан референдум үткәрелми.

12 статья. Референдум үткәрү инициативасы

1. Референдум үткәрү инициативасы белән түбәндәгеләр чыга ала:

референдумда катнашу хокукына ия гражданнар;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы халык депутатларының билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән бер өлеше;

Татарстан Республикасы Президенты;

иҗтимагый берләшмәләр.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән субъектлар референдум үткәрү инициаторлары булып тора.

13 статья. Референдум үткәрү турында гражданнарның, иҗтимагый берләшмәләрнең инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе

1. Референдумда катнашу хокукына ия һәр граждан яисә гражданнар төркеме, шулай ук референдум үткәрү инициативасы белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать иткән көнгә кадәр алты айдан да соңга калмыйча юстиция органнары тарафыннан теркәлгән, уставында сайлауларда катнашу каралган иҗтимагый берләшмә референдумда катнашу хокукына ия кимендә 20 гражданнан торган,

референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю өчен референдум үткәрү буенча инициатив төркем төзергә мөмкин.

2. Республика дәрәҗәсендә яисә федераль дәрәҗәдә юстиция органында теркәлгән сайлау берләшмәсе шулай ук референдум үткәрү инициаторы буларак чыгарга мөмкин. Мондый очракта сайлау берләшмәсенең җитәкче органы йә аның төбәк, җирле бүлегенең, җирле оешмасының җитәкче органы үзенең санлы составына карамастан референдум үткәрү буенча инициатив төркем буларак чыга.

3. Референдумны билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә референдумны үткәрү инициативасын хуплап анда катнашучыларның имзалары бирелергә тиеш.

4. Референдумны үткәрү буенча инициатив төркем (алга таба - инициатив төркем) инициатив төркемне теркәү турындагы үтенечнамә белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итә.

5. Инициатив төркем үтенечнамәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) референдумга чыгарылу өчен тәкъдим ителүче (ителгән) сорауның (сорауларның) йә закон проекты текстының язмача бирелеше;

2) инициатив төркем әгъзаларының, шулай ук инициатив төркем исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынындагы адресы, паспортының яисә аны алмаштыручы башка документының сериясе һәм номеры.

6. Үтенечнамәгә инициатив төркемнең референдум үткәрү инициативасы белән чыгу хакында карар кабул ителгән җыелышының беркетмәсе кушымта итеп бирелергә тиеш.

7. Инициатив төркем тарафыннан референдумга чыгару өчен тәкъдим ителә торган сорау әлеге Закон таләпләренә җавап бирмәсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сорауның төп эчтәлеген үзгәртмичә инициатив төркем белән яңа формулировканы килештерергә мөмкин. Референдумга чыгарылучы сорауның формулировкасын үзгәртү хокукы бары тик инициатив төркемгә генә бирелә. Референдумга чыгарылучы сорауның формулировкасы инициатив төркем теркәлгәннән соң үзгәртелә алмый.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркем үтенечнамәсе алынганнан соң 15 көн эчендә әлеге үтенечнамәне һәм аңа

кушылып бирелгән документларны карарга һәм түбәндәге карарны кабул итәргә тиеш:

күрсәтелгән үтенечнамә һәм документлар Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм федераль законнар таләпләренә туры килгән очракта - аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрү турында;

киресенчә булган очракта - инициатив төркемне теркәүне кире кагу турында.

9. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы референдумга чыгарылу өчен тәкъдим ителүче сорауның, алынганнан соң 20 көн эчендә әлеге статьяның 8 пунктында каралган тәртиптә бу Законның 10 статьясы таләпләренә туры килүен, инициатив төркемнең үтенечнамәсен һәм аңа кушып бирелгән документларны тикшерергә тиеш.

10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге статьяның 8 пунктында каралган тәртиптә инициатив төркем үтенечнамәсе һәм аңа кушып бирелә торган документлар алынганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча әлеге инициатива хакында Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итәргә тиеш.

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы референдумга чыгарыла торган сорауны әлеге Законның 10 статьясындагы таләпләргә җавап бирә дип таныган очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемне терки, аңа теркәлү таныклыгын тапшыра, шулай ук бу хакта массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә. Инициатив төркемне теркәү турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советына инициатив төркемнең үтенечнамәсе һәм аңа кушып бирелгән документлар кергәннән соң 45 көн үткәч унбиш көн эчендә кабул ителә.

12. Референдум үткәрү инициативасы белән чыгуга бәйле рәвештә компетенция турында бәхәс килеп чыккан очракта Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте Татарстан Республикасы Дәүләт Советына килештерү

комиссиясе төзергә тәкъдим итәргә хокуклы. Килештерү комиссиясе эшендә инициатив төркем вәкилләре катнашырга хокуклы. Килештерү комиссиясе эшләгән вакытта әлеге статьяның 11 пунктында күрсәтелгән вакыт туктатып торыла.

13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы референдумга чыгарыла торган сорауны әлеге Законның 10 статьясы таләпләренә җавап бирми дип таныган очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемне теркәүдән баш тарта.

14. Теркәүдән баш тарткан очракта, баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, инициатив теркемгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары бирелә.

15. Инициатив төркемнең Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе Конституциясен, әлеге Законны,Татарстан Республикасының башка законнарын, федераль законнарны бозу гына инициатив төркемне теркәүдән баш тартуга нигез булырга мөмкин. Теркәүдән баш тарткан өчен судка шикаять бирелергә мөмкин.

16. Теркәлү таныклыгын алган мизгелдән инициатив төркем, референдум үткәрү инициативасын хуплап, гражданнарның имзаларын җыюны оештырырга хокуклы. Монда инициатив төркемне теркәү көненнән соң җыелган имзалар гына исәпкә алына. Формасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана торган һәм инициатив төркемгә бирелә торган теркәү таныклыгы 35 көн дәвамында гамәлдә була. Имзалар җыюга бәйле чыгымнарны инициатив төркем түли, чыгымнар бары тик рферендумда катнашу фонды акчалары исәбеннән генә түләнергә тиеш.

17. Референдум үткәрү инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны референдумда катнашу хокукына ия гражданнарның 2 процентын тәшкил итә. Референдумда катнашу хокукына ия гражданнарның саны тиешле елның 1 гыйнварына яисә 1 июленә референдумда катнашучыларны теркәү белешмәләре нигезендә билгеләнә.

18. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю чоры инициатив төркемгә теркәү таныклыгын биргәннән соң 30 көн дәвам итә. Имзалар җыю тәмамланганнан соң, әмма теркәү таныклыгының гамәлдә булу чоры тәмамланганчы, инициатив төркем җыелган имзаларның

264

гомуми санын исәпли, бу хакта инициатив төркемнең йомгаклау беркетмәсе төзелә. Номерланган һәм төпләнгән имза кәгазьләре һәм инициатив төркемнең йомгаклау беркетмәсе нөсхәсе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре тарафыннан Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

19. Бирелгән имзалар саны имзаларның тиешле санының 15 процентыннан артып китә алмый.

20. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе имзалар җыйганда әлеге Закон таләпләрен үтәүне, шул исәптән җыелган имзаларның дөрес булуын да тикшерә һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул итә. Күрсәтелгән таләпләрне бозу ачыкланган очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдум үткәрүдән баш тарту турында карар чыгара. Әлеге карарның күчермәсе инициатив төркемгә җибәрелә. Бу инициатив төркем әгъзалары әлеге карар кабул ителгән көннән соң ике ел дәвамында референдум үткәрү инициативасы белән кабат чыга алмый.

21. Имзалар җыйганда әлеге Закон таләпләре бозылмаса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге статьяның 18 пунктында күрсәтелгән документларны инициатив төркемгә биргәннән соң 15 көн дәвамында инициатив төркемнең йомгаклау беркетмәсе нөсхәсен һәм үз карарының күчермәсен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары күчермәсе шулай ук инициатив төркемгә дә җибәрелә.

<u>14 статья.</u> Референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю тәртибе

1. Имзалар референдумга чыгарыла торган сорау язылган имзалар кәгазенә кул кую юлы белән җыела. Референдумга закон проекты чыгарылган очракта, имзаларны җыючы зат әлеге проект текстын референдумда катнашучының беренче таләбе буенча бирергә тиеш.

2. Имзалар кәгазе әлеге Законның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән рәвештә әзерләнә.

3. Имзалар референдумда катнашучылар арасында Татарстан Республикасының бөтен территориясендә җыела. Имзалар җыюда предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның администрацияләре катнашуга, шулай ук имзалар җыю барышында мәҗбүр итүгә һәм имза керткән өчен бүләкләүгә юл куелмый. Хезмәт хакын бирү барышында һәм урыннарында имзалар җыю тыела.

4. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю хокукына балигъ булган хокукый сәләтле граждан ия була.

5. Референдумда катнашучы имзалар кәгазендә үзенең фамилиясен,исемен, атасының исемен, туган елын (18 яшендә булса - өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урынындагы адресын, паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясен һәм номерын, аның бирелү датасын күрсәтә, шулай ук имза сала, датасын куя. Референдумда катнашучы турындагы мәгълүмат кулдан языла һәм имзалар җыючы зат тарафыннан имзалар кәгазенә кертелергә мөмкин.

6. Һәр имзалар кәгазе гражданнарның имзаларын җыючы зат һәм инициатив тәркемнең берәр вәкаләтле заты имзасы белән расланырга тиеш, анда раслауның датасы, бу затларның һәркайсының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынындагы адресы, паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелергә тиеш.

## <u>15 статья</u> Гражданнарның референдум үткәрү инициативасын хуплаган имзаларын тикшерү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдум үткәрү инициативасын хуплап җыелган имзаларның дөреслеген тикшерә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча әлеге тикшерүне үткәрү өчен халык исәбен алып баручы белгечләр, эчке эшләр органнары, бүтән учреждениеләр һәм оешмалар экспертлары җәлеп ителергә мөмкин. Аларның язма бәяләмәләре имза кәгазьләрендәге имзаларны һәм алардагы тиешле белешмәләрне дөрес түгел дип тану өчен нигез булырга мөмкин. Күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланырга мөмкин.

2. Тәкъдим ителгән барлык имзалар йә шул имзаларның бер өлеше, әмма әлеге Законның 13 статьясындагы 17 пунктында билгеләнгән тиешле имзаларның тикшерү өчен очраклы тартып чыгару (жирәбә салу) юлы белән аралап алынган санының кимендә 20 проценты тикшерелергә тиеш. Очраклы тартып чыгару процедурасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе утырышында имзаларны тикшерү өчен тартып чыгару (жирәбә салу) һәм тикшерү вакытында инициатив төркемнең имзалар биргән барлык вәкаләтле вәкилләре, инициатив төркем әгъзалары катнашырга хокуклы. Һәр тикшерүнең вакыты турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтелгән затларга хәбәр итәргә тиеш. Тикшерү өчен алынган имза кәгазьләрендәге барлык имзалар да тикшерелергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә имзалар бирелгәнче инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имза кәгазьләреннән төшереп калдырылган (сызылган) имзалар, әгәр алар тарафыннан махсус билгеләнгән булсалар, тикшерелмиләр һәм исәпкә алынмыйлар.

4. Имза кәгазьләрен аралап тикшергәндә референдум үткәрү инициативасын хуплап бер үк затның берничә тапкыр имза салуы ачыкланса, бер генә имза исәпкә алына.

5. Түбәндәге имзалар дөрес түгел дип санала:

а) референдумда катнашу хокукына ия булмаган затларның имзалары һәм имзалар кәгазендә дөреслеккә туры килми торган мәгълүмат биргән референдумда катнашучыларның имзалары. Бу очракта эчке эшләр органының рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 1 пункты нигезендә имзаларның дөреслеген тикшерү эшенә җәлеп ителгән экспертның бәяләмәсе булса, имза дөрес түгел дип таныла;

б) әлеге Закон нигезендә таләп ителә торган белешмәнең кайсы да булса күрсәтелмәсә йә имза салган референдумда катнашучының үз имзасын салу датасы күрсәтелмәсә;

в) референдумда катнашучыларның төрле затлар исеменнән бер зат яисә бер зат исеменнән башка зат салган имзалары;

г) референдумда катнашучыларның имзалар кәгазенә кулдан язылмаган яисә карандаш белән язылган имзалары;

267

д) референдумда катнашучы һәм имзалар кәгазен таныклаучы затлар тарафыннан имзалар кәгазендә имза салу датасы төзәтелгән булса, әгәр бу төзәтүләр референдумда катнашучы һәм имза кәгазьләрен раслаучы затлар белән килешенмәсә, шулай ук референдумда катнашучылар имза салу датасын үз куллары белән язмасалар, референдумда катнашучыларның имзалары;

е) референдумда катнашучыларның референдумда катнашучылар турында үзләренә тиешле белешмәләрне төзәткән имзалары, әгәр ул төзәтмәләр референдумда катнашучы яисә имза кәгазьләрен таныклаучы затлар тарафыннан махсус килешенмәгән булса;

ж) имзалар җыйган зат һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле имзалар кәгазен үз кулы белән имза салып расламаса, йә әлеге имза дөрес булмаса яки имзалар җыйган зат турындагы мәгълүматта, имзалар җыйган затның, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең имза салу датасында, имзалар җыйган зат, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килешенмәгән төзәтмәләр булса, имзалар кәгазендәге барлык имзалар.

6. Тикшерелә торган имзалар арасында тикшерелгән имзалар санының 15 проценттан артыграк өлеше дөрес булмаган имзалар дип танылганда яисә дөрес имзаларның саны җитәрлек булмаганда, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдум үткәрүдән баш тарту турында карар чыгара.

**<u>16 статья.</u>** Татарстан Республикасы халык депутатларының референдум үткәрү турындагы инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе

1. Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советының билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән бере күләмендә референдум үткәрү турында инициатива белән чыгарга хокуклы. Бу очракта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына: референдум үткәрү инициаторы булып чыккан һәр Татарстан Республикасы халык депутатының фамилиясе, исеме, атасының исеме, референдум үткәрүнең зарурлыгына нигезләмә, референдумга тәкъдим ителә торган

сораунын (сорауларнын) һәм (яисә) закон проекты тексты формулировкасы күрсәтелеп, халык депутатларының имзалары исемлеге бирелә.

2. Референдум үткәрү инициаторлары булган Татарстан Республикасы халык депутатлары референдум билгеләнгәннән соң референдум үткәрүне әзерләүгә бәйле үгетләүләр һәм башка гамәлләр башкару өчен референдум үткәрү буенча гражданнар төркеме төзергә мөмкин. Референдум үткәрү буенча гражданнар төркеменең, шулай ук төркем исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның составы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынының адресы, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелеп, референдум үткәрү инициаторлары булып торган Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан раслана һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә. Әлеге төркем граждан, гражданнар төркеме яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан төзелгән инициатив төркем өчен бу Законда каралган хокуклардан файдалана.

<u>17 статья.</u> Татарстан Республикасы Президентының референдум үткәрү турындагы инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе

1. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына референдум үткәрү турында, аны үткәрү зарурлыгын нигезләп, референдумга тәкъдим ителә торган сораунын (сорауларнын) һәм (яисә) закон проекты текстының формулировкасы белән тәкъдим кертә.

2. Татарстан Республикасы Президенты әлеге Законның 16 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә референдум үткәрү буенча гражданнар төркеме төзергә мөмкин.

<u>18 статья.</u> Референдумны билгеләү

1. Референдумны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгели.

2. Референдум үткәрү турындагы яисә референдум үткәрү инициативасын кире кагу турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы пленар сессиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт

Советына референдум үткәрү турында материаллар бирелгән көннән соң ике ай эчендә кабул ителә.

3. Референдум үткәрү турындагы инициатива белән чыкканда Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка законнары таләпләре бозылган очракта гына Дәүләт Советы референдумны билгеләүдән баш тартырга хокуклы.

4. Инициатив төркем вәкиле референдум билгеләү турындагы мәсьәлә тикшерелгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның органнары утырышларында катнашырга хокуклы.

5. Референдум бары тик календарь ял көненә генә билгеләнә. Бәйрәм көненә референдум билгеләнүгә юл куелмый. Референдум үткәрү турындагы карарда референдум үткәрү көне билгеләнә. Референдум үткөрү турындагы карар тавыш бирү көненә кадәр кимендә 60 көн кала рәсми басылып чыгарылырга тиеш.

6. Референдумда тавыш бирүне үткәрү көне референдум үткәрүгә 25 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән референдум үткәрүне икенче референдум (Россия Федерациясе референдумы моңа керми) йә дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрү белән берләштерү максатларында соңрак вакытка (ләкин 90 көннән дә соңракка түгел) күчерелергә мөмкин.

Тавыш бирү көнен күчерү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында, карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, басылып чыга.

## III бүлек. Референдум комиссияләре

### <u>19 статья.</u> Референдум комиссияләре системасы һәм статусы

1. Референдум әзерләүне һәм үткәрүне түбәндәгеләр башкара:

Татарстан Республикасы Үзәк референдум комиссиясе буларак эш итүче Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе;

территория (район, шәһәр, шәһәрләрдәге район) референдум комиссияләре (алга таба - территория комиссияләре);

участок референдум комиссияләре (алга таба - участок комиссияләре).

2. Референдум комиссияләре референдум әзерләү һәм үткәрү барышында үзләренә әлеге Законның бозылуы турында алынган мөрәҗәгатьләрне үз компетенцияләре чикләрендә карарга һәм тикшерергә тиеш, мөрәҗәгать юллаган затларга биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көне алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш бирү көнендә яисә тавыш биргән көннең иртәгәсендә кичекмәстән язма җаваплар бирергә тиеш. Әгәр мөрәҗәгатьләрдәге фактлар өстәмә тикшерелүне таләп итсә, алар буенча карарлар ун көннән дә соңга калмыйча кабул ителә. Референдум комиссияләре федераль закон нигезендә тиешле тикшерү үткәрү һәм әлеге Закон бозуны булдырмау турындагы тәкъдим белән хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы, алар исә биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көне алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча, ө тавыш бирү көнендә яисә тавыш бирү көненең иртәгәсендә кичекмәстән әлеге хокук бозуларны булдырмау чаралары күрергә тиеш. Әгәр мөрәҗәгатьтәге фактлар өстәмә тикшерүне таләп итсә, әлеге чаралар федераль закон нигезендә ун көннән дә соңга калмыйча күрелә.

3. Референдум комиссияләре референдумда катнашучыларны референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле гамәлләрне башкару вакытлары һәм тәртибе турында, референдум әзерләү һәм үткәрү барышы хакында мәгълүмат белән тәэмин итәләр.

4. Югарырак референдум комиссиясенең үз компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарлары түбәнгерәк референдум комиссияләре өчен мәҗбүри.

5. Референдум комиссиясенең законга каршы килеп йә билгеләнгән вәкаләтләрне арттырып кабул ителгән карары югарырак референдум комиссиясе яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш. Бу очракта югарырак референдум комиссиясе мәсьәләнең асылы буенча карар кабул итәргә хокуклы.

6. Референдум комиссияләре үз компетенцияләре чикләрендә дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан бәйсез була.

7. Референдум комиссияләренең үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән карарлары һәм актлары башкарма хакимият органнары, дәүләт учреждениеләре, җирле үзидарә органнары,сайлау берләшмәләре,

иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, урындагы затлар һәм референдумда катнашучылар өчен мәҗбүри.

8. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт катнашы булган учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр, шулай ук аларның урындагы затлары референдум комиссияләренә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, аерым алганда, кирәкле бина, транспорт, элемтә чаралары, техник җиһаз, белешмәләр һәм материаллар бирүгә ярдәм итәргә, референдум комиссияләренең мөрәҗәгатьләренә биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көне алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш бирү көнендә яисә тавыш биргән көннең иртәгәсендә кичекмәстән җаваплар бирергә тиеш. Теле- һәм (яисә) радио тапшыруларын гамәлгә ашыручы оешмалар һәм әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре референдум комиссияләренең басма мәгълүматын урнаштыру мөмкинлеге, шулай ук референдум комиссияләренә референдумда катнашучыларга җиткерү өчен түләүсез эфир вакыты бирергә тиеш. Бу очракта теле- һәм (яисә) радио тапшыруларын гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләренең чыгымнары әлеге Законның 36 статьясындагы 4 пункты һәм 37 статьясындагы 1 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә каплана. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелмәгән иҗтимагый берләшмәләр, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар теле- һәм (яисә) радио тапшыруларын гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, шулай ук аларның урындагы затлары биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көне алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш биргән көнне яисә тавыш биргән көннең иртәгәсендә кичекмәстән референдум комиссияләренә кирәкле мәгълүматны һәм материалларны бирергә, референдум комиссияләре мөрәҗәгатьләренә җаваплар бирергә тиеш.

<u>20 статья.</u> Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

1. Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Үзәк

сайлау комиссиясе референдум комиссияләренең референдум әзерләүне һәм үткәрүне гамәлгә ашыручы эшчәнлегенә юнәлеш бирә.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Законы, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендәге башка законнар белән билгеләнә.

21 статья. Территория комиссияләрен төзү тәртибе һәм аларның вәкаләтләре чоры

1. Территория комиссияләре, референдум билгеләү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары басылып чыккач 15 көннән дә соңга калмыйча, референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 10-16 әгъзасы составында сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының, иҗтимагый берләшмәләрнең, яшәү, эшләү, хезмәт итү һәм уку урыннары буенча сайлаучылар җыелышларының, җирле үзидарәнең сайлаулы органнары тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Территория комиссияләре әгъзаларының яртысы - халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары тарафыннан, икенче яртысы тиешле җирле администрация башлыгы тарафыннан билгеләп куела.

2. Халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы һәм җирле администрация башлыгы Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында фракцияләре булган сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләре булган сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә үзләре билгеләп куя торган территория комиссиясе әгъзаларының кимендә өчтән бер өлешен билгеләп куярга тиешләр. Бу очракта территория комиссиясенә сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан бердән артык вәкил билгеләнеп куела алмый.

3. Әгәр халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советы һәм тиешле җирле администрация башлыгы территория комиссиясе составын йә территория комиссия составының бер өлешен күрсәтелгән вакытка билгеләп куймаса яисә әлеге территориядә шушы орган булмаса, терри-

тория комиссиясе составын йә аның бер өлешен билгеләп кую, әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

4. Әгәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе адресына әлеге референдум комиссиясенең тавыш бирү һәм тавышларны санау тәртибен бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр һәм протестлар алынмаган булса һәм әлеге фактлар буенча судта тикшерү алып барылмаса, референдум нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыккач 15 көннән соң территория комиссиясенең вәкаләтләр чоры туктатыла. Тавыш бирү йомгакларына карата шикаять яисә протест белдерелгән очракта, территория комиссиясенең вәкаләтләре югарырак комиссия яисә суд тарафыннан шикаятьнең, протестның асылы буенча катгый карар чыгарылганнан соң туктатыла.

<u>22 статья.</u> Участок комиссияләрен төзү тәртибе һәм аларның вәкаләтләре чоры

1. Участок комиссияләре, референдум участогы төзелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының, иҗтимагый берләшмәләренең , яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыннары буенча сайлаучылар җыелышларының тәкъдимнәре һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары тәкъдимнәре нигезендә референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 8-12 әгъзасы составында җирле үзидарәнең вәкиллекле органы (вәкиллекле органнары) тарафыннан төзелә. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органы (вәкиллекле органнары) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында фракцияләре булган сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм (яисә) җирле үзидарәнең вәкиллекле органында (вәкиллекле органнарында) фракцияләре булган сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә участок комиссиясе составының кимендә өчтән берен билгеләп куярга тиеш. Бу очракта сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәркайсыннан бердән артык вәкил билгеләнеп куела алмый.

274

2. Әгәр җирле үзидарәнең вәкиллекле органы билгеләнгән вакытка участок комиссиясенең составын йә составының бер өлешен билгеләп куймаса йә әлеге территориядә шушы орган булмаса, участок комиссиясенең составын йә составының бер өлешен билгеләп кую, әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәп, тиешле территория комиссиясе тарафыннан башкарыла.

3. Әгәр югарырак референдум комиссиясе адресына әлеге референдум комиссиясенең тавыш бирү һәм тавышларны санау тәртибен бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр һәм протестлар алынмаган булса һәм әлеге фактлар буенча судта тикшерү алып барылмаса, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккач 10 көннән соң участок комиссиясенең вәкаләтләре чоры туктатыла. Тавыш бирү йомгакларына карата шикаять яисә протест белдерелгән очракта, участок комиссиясенең вәкаләтләре югарырак комиссия яисә суд тарафыннан шикаятьнең, протестның асылы буенча катгый карар чыгарылганнан соң туктатыла.

23 статья. Территория комиссиясенең вәкаләтләре

Территория комиссиясе:

1) тиешле территориядә референдум әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

2) референдумда катнашучыларның исемлекләрен төзи;

3) участок комиссияләренең адресларын һәм телефон номерларын халыкка җиткерә;

4) тиешле территориядә участок комиссияләренең эшен җайга сала, әлеге комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм алар буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

5) референдум әзерләү һәм үткәрү өчен бүлеп бирелгән акчалар белән эш итә һәм аларны участок комиссияләренә бүлеп бирә, аларның максатчан кулланылуын тикшереп тора;

6) тавыш бирү бюллетеньнәрен һәм башка документларны участок комиссияләренә илтеп җиткерүне оештыра;

7) референдум участокларында тавыш бирүне оештырганда участок комиссияләренә оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

8) тиешле территориядә референдумда тавыш бирү йомгакларын билгели, аларны массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыра;

9) референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле документларны саклауны һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә архивка тапшыруны тәэмин итә;

10) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

24 статья. Участок комиссиясенең вәкаләтләре

Участок комиссиясе:

1) участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры, эш вакыты турында, шулай ук тавыш бирү көне һәм урыны турында халыкка хәбәр итә;

2) референдум участогы буенча референдумда катнашу хокукына ия гражданнарның исемлеген төгәлләштерә;

3) гражданнарны референдумда катнашучылар исемлеге белән таныштыра, әлеге исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турында гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакындагы мәсьәләне хәл итә;

4) тавыш бирү өчен бина әзерләүне һәм җиһазлауны тәэмин итә;

5) референдум участогы территориясендә үгетләү тәртибенең үтәлешен тикшереп тора;

6) референдум участогында тавыш бирүне оештыра;

7) тавышларны санауны үткәрә, референдум участогы буенча тавыш бирү йомгакларын билгели һәм тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи һәм аны тиешле территория комиссиясенә тапшыра, документларны архивка тапшыру өчен әзерли;

8) әлеге Законны бозу турындагы шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм алар буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

9) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

276

25 статья. Референдум комиссияләре әгъзаларының статусы

1. Дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутатлары, җирле үзидарә органнары депутатлары, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайланулы урындагы затлары, судьялар, инициатив төркемнәрнең вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары, референдум комиссияләренең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары була алмыйлар.

2. Дәүләт хезмәткәрләре һәм җирле үзидарә органнарында эш урыннарын биләүче затлар территория, участок комиссиясе әгъзаларының гомуми санының өчтән береннән артыграгын тәшкил итә алмыйлар.

3. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы бер үк вакытта югарырак яисә түбәнгерәк референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы була алмый.

4. Референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләр чоры әлеге референдум комиссияләренең вәкаләтләре туктатылу белән бер вакытта тәмамлана.

5. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы референдум комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан аны билгеләп куйган органның карары белән вәкаләтләр чоры тәмамланганчы ук түбәндәге очракларда азат ителә:

референдум комиссиясе әгъзасы үз вәкаләтләрен туктатуы хакында язмача гариза биргәндә;

референдум комиссиясе әгъзасы Россия Федерациясе гражданлыгын югалтканда;

референдум комиссиясе әгъзасына карата судның гаепләүче хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә референдум комиссиясе әгъзасы хокукый сәләтсез, хокукый сәләте чикләнгән дип, хәбәрсез югалган яисә вафат булган дип танылганда;

референдум комиссиясе әгъзасы вафат булганда;

тиешле референдум комиссиясе гаризасы, закон көченә кергән суд карары нигезендә референдум комиссиясе әгъзасы даими рәвештә үз вазыйфаларын үтәмәүче дип танылганда;

әлеге статьяның 1 пунктында каралган төрле нигезләр килеп чыкканда.

6. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының вәкаләтләре шулай ук әлеге Законның 26 статьясы нигезендә референдум комиссиясе таркатылган очракта да тәмамлана.

7. Референдум комиссиясе әгъзасын билгеләп куйган орган алда күрсәтелгән сәбәпләр аркасында киткән референдум комиссиясе әгъзасы урынына, ул киткәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча, әлеге Законда билгеләнгән таләпләр нигезендә референдум комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләп куярга тиеш. Шуңа вәкаләтле орган әлеге таләпне үтәмәгән очракта, югарырак референдум комиссиясе, бу Законда билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш, референдум комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләп куя.

8. Референдум комиссиясенең референдум әзерләү һәм үткәрү чорына төп эшеннән азат ителгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасының төп эш урыны буенча уртача хезмәт хакы саклана. Референдум комиссиясенең референдум әзерләү һәм үткәрү чорында төп эшеннән азат ителгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына хезмәт өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасының республика бюджетыннан референдум үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән күләмнәрдә һәм тәртиптә башкарылырга мөмкин.

9. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы референдум үткәрү чорында Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына яки суд тәртибендә билгеләнүче административ җәза гамәлләренә тартыла алмый.

10. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы референдум үткәрү чорында администрация (эш бирүче) инициативасы белән эшеннән азат ителә алмый яисә үз ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелә алмый.

278

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан референдум үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң референдум үткәрү инициаторы яисә инициатив төркем, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вәкилләре булган сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары референдум комиссияләренә референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия бер әгъзасын билгеләп куярга хокуклы.

12. Референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы референдум әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы хокукларына тулаем ия була, моңа түбәндәге хокуклар керми:

референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен тарату;

референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен сортларга аеруда һәм санауда катнашу;

тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзүдә катнашу;

референдумның тиешле комиссиясе компетенциясенә караган мәсьәлә буенча карар кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашу;

референдум комиссиясе карарларына имза салу.

13. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзасы:

тиешле референдум комиссиясе утырышлары хакында алдан хәбәр ала;

референдум комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле референдум комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирү уздыруны таләп итәргә хокуклы;

референдум комиссиясе утырышындагы башка катнашучыларга көн тәртибе нигезендә сораулар бирергә һәм аларга төпле җаваплар алырга хокуклы;

тиешле һәм түбәнгерәк референдум комиссияләренең, машинадан укыла торган саклагычлардагы документларны һәм материалларны да кертеп, теләсә кайсы документлары һәм материаллары (шул исәптән референдумда катнашучыларның исемлекләре, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре), һәм шушы документларның, материалларның

279

(референдумда катнашучыларның исемлекләреннән, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәреннән кала) күчермәләрен алырга, бу күчермәләрне раслауны таләп итәргә хокуклы;

референдум комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата тиешле югарырак комиссиягә яисә судка шикаять белдерергә хокуклы.

14. Референдум комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккач 10 көннән соң туктатыла.

15. Референдум комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзасының вәкаләтләре референдум комиссиясенең шушы әгъзасын билгеләп куйган инициатив төркем яисә орган карары буенча тукталырга һәм башка затка тапшырылырга мөмкин.

<u>26 статья.</u> Референдум комиссиясен тарату

1. Территория, участок комиссиясе гражданнарның референдумда катнашу хокукларын, тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын йә референдум нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә (шулл исәптән суд карары нигезендә дә) гамәлгә яраксыз дип таныrлык итеп бозган очракта, күрсәтелгән референдум комиссиясе федераль законда билгеләнгән хөкем нигезендә суд тарафыннан таратылырга мөмкин.

2. Территория, участок комиссиясен тарату турындагы гариза белән судка Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, шулай ук Татарстан Республикасы халык депутатларының гомуми саныннан кимендә өчтән бере составындагы Татарстан Республикасы халык депутатлары төркеме, йә Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларының гомуми саныннан кимендә өчтән бере составындагы Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары төркеме, йә җирле үзидарәнең тиешле вәкиллекле органы депутатларының гомуми саныннан кимендә өчтән бере составындагы әлеге орган депутатлары төркеме, шулай ук федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Комиссияне тарату турындагы гариза кичекмәстән карауга кабул ителә һәм аның буенча карар 14 көннән дә соңга калмыйча чыгарыла. Референдум комиссиясен тарату турындагы эш суд тарафыннан коллегиаль рәвештә карала.

4. Вәкаләтләренә референдум комиссиясен тарату кергән дәүләт хакимияте органнары йә җирле үзидарә органы референдум комиссиясен тарату турындагы суд карары үз көченә кергәннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча тиешле референдум комиссиясе төзергә тиеш.

5. Референдум комиссиясен тарату тиешле референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләрен туктатуга китерми.

<u>27 статья.</u> Референдум комиссияләре эшчәнлегендә хәбәрдарлык

1. Тиешле референдум комиссиясенең барлык утырышларында, шулай ук референдумда катнашучыларның исемлекләре, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре, референдумда тавыш бирү өчен бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр белән тиешле участок, территория комиссиясе тарафыннан эш башкарылганда югарырак референдум комиссияләре әгъзалары, инициатив төркем әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле, референдум үткәрүнең башка инициаторларының вәкаләтле вәкилләре катнашырга хокуклы. Утырышларда катнашу өчен һәм референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле күрсәтелгән документлар буенча эш башкарганда әлеге затларга өстәмә рөхсәт таләп ителми. Тиешле референдум комиссиясе хәбәрләшүне һәм әлеге затларның утырышларга ирекле керә алуын һәм референдум әзерләүгә, үткәрүгә бәйле күрсәтелгән документлар белән эшләгәндә алардан ирекле файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Утырышларда һәм референдум әзерләүгә, үткәрүгә бәйле күрсәтелгән документлар белән эш башкарганда шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

2. Референдум комиссияләренең карарлары әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында 5 көн эчендә матбугатта әлеге массакүләм мәгълүмат

281

чараларының агымдагы бюджет финанслануы акчалары исәбеннән басты-рылып чыга һәм башка массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

3. Тавыш бирү көнендә участок комиссиясе эш башлаган мизгелдән алып югарырак референдум комиссиясе тарафыннан тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең кабул итеп алынуы хакында хәбәр алынганга кадәр, шулай ук референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санаганда референдум участокларында әлеге статьяның 1 пунктында санап үтелгән затлар, шулай ук күзәтүчеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, чит ил (халыкара) күзәтүчеләре катнашырга хокуклы.

4. Хәрби частьтәге, ябык административ-территория берәмлегендәге, хастаханәдәге, шифаханәдәге, ял йортындагы, тикшерү һәм вакытлыча тоту изоляторларындагы референдум участогында төзелгән участок комиссиясе бинасына, шулай ук бу референдум участогындагы тавыш бирү бинасына референдум комиссиясенең барлык әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән башка затларга кереп йөрү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

5. Күзәтүчеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, чит ил (халыкара) күзәтүчеләре башка референдум комиссияләрендә, алар тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә, референдум нәтиҗәләрен ачыклаганда, тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре турында тиешле беркетмәләр төзегәндә, шулай ук референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санаганда катнашырга хокуклы.

6. Иҗтимагый берләшмә, инициатив төркем, референдум үткәрү инициаторы тарафыннан үз мәнфәгатьләрен чагылдырган күзәтүченең вәкаләтләре, аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, тору урыны, шулай ук ул җибәрелгән референдум участогының номеры, референдум комиссиясенең исеме күрсәтелеп, язма рәвештә таныкланырга тиеш. Әлеге документ паспорт яисә аны алыштыручы документны күрсәткәндә генә дөрес була. Күзәтүче җибәрү турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

7. Әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән документлар участок комиссиясенә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорга, территория референдум комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында

282

беркетмә төзү эше башланганнан алып әлеге эш тәмамланганчы бирелергә мөмкин.

8. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) референдумда катнашучыларның исемлеге белән танышырга;

б) тавыш бирү көнендә тиешле референдум участогында тавыш бирү бинасында әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорда теләсә кайсы вакытта булырга;

в) референдумда катнашучылар тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргәндә катнашырга;

г) референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнарны, референдумда катнашучыларга бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен, референдумда тавыш бирү өчен файдаланылган бюллетеньнәрне санауны күзәтергә; референдум участогында тавыш бирү бюллетеньнәренең эчтәлеге үзләренә күренерлек ераклыкта һәм шартларда референдумда катнашучылар тавышларын санауны күзәтеп торырга; референдумда катнашучылар тавышларын санаганда теләсә кайсы тутырылган яисә тутырылмаган бюллетень белән танышырга; референдум комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә һәм әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорда башка документлар төзүен күзәтергә;

д) участок комиссиясе рәисенә, ә ул булмаганда - аны алыштыручы затка тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белән мөрәҗәгать итәргә;

е) участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе белән, шулай ук башка референдум комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары һәм нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән танышырга; күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән документларның, шулай ук тиешле референдум комиссияләренә кергән башка документларның йә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорда шушы комиссияләр тарафыннан төзелгән документларның күчермәләрен, шул исәптән тавыш бирүдә катнашкан затларның исемлеген дә, әзерләтергә яисә тиешле референдум комиссиясеннән соратып алырга. Күзәтүче таләбе буенча референдум комиссиясе күрсәтелгән күчермәләрне бирергә яисә расларга тиеш;

283

ж) референдум комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата территория референдум комиссиясенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, шулай ук федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясенә яисә судка шикаять бирергә;

з) референдумда катнашучылар тавышларын тиешле комиссияләрдә кабат санаганда катнашырга.

8. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы булмый:

а) референдумда катнашучыларга референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен бирергә;

б) референдумда катнашучы үтенече буенча референдумда тавыш бирү бюллетенен алган өчен аның урынына имза салырга;

в) референдумда катнашучы үтенече буенча референдумда тавыш бирү бюллетенен тутырырга;

г) тавыш бирү яшеренлеген бозарлык гамәлләр кылырга;

д) референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен санаганда турыдан-туры катнашырга;

е) референдум комиссиясе эшенә комачауларлык гамәлләр кылырга;

ж) референдумда катнашучылар арасында үгетләү алып барырга;

з) тиешле референдум комиссиясе карарлар кабул иткәндә катнашырга.

10. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре белән, шулай ук башка референдум комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы яисә референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән танышырга йә күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән башка документларның күчермәләрен әзерләргә йә тиешле референдум комиссиясеннән алырга хокуклы. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкиле таләбе буенча референдум комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында яисә референдум нәтиҗәләре турында беркетмәнең күчермәсен распарга тиеш.

11. Референдум комиссияләре беркетмәләренең һәм башка төрле документларның күчермәләрен раслау референдум комиссиясе рәисе яисә секретаре тарафыннан башкарыла. Раслана торган документка күрсәтелгән

284

затлар «күчермә дөрес» дип язалар, имза салалар һәм тиешле референдум комиссиясенең мөһерен сугалар.

12. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләре Татарстан Республикасына керү өчен федераль законда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алалар, дәүләт хакимияте органнарының,референдум комиссияләренең чакырулары булганда, алар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләренең эшчәнлеге федераль конституциячел законнар һәм федераль законнар белән җайга салына.

28 статья. Референдум комиссияләренең эшчәнлеген оештыру

1. Референдум комиссияләренең эшчәнлеге коллегиаль рәвештә гамәлгә ашырыла.

2. Билгеләнгән составының кимендә өчтән икесе төзелгәч, референдум комиссиясе эшкә керешергә тулы хокуклы була.

3. Референдум комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре аның беренче утырышында референдум комиссиясе әгъзалары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

4. Референдум комиссиясе утырышлары рәис тарафыннан яисә аның кушуы буенча референдум комиссиясе рәисе урынбасары тарафыннан, шулай ук референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының кимендә өчтән бере таләбе буенча чакырыла.

5. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы референдум комиссиясенең барлык утырышларында да катнашырга тиеш.

6. Әгәр референдум комиссиясе утырышында референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелеге катнашса, ул утырыш тулы хокуклы була.

7. Тиешле референдум комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасының, шулай ук югарырак референдум комиссиясенең утырышта катнашучы теләсә кайсы әгъзасының таләбе буенча референдум комиссиясе үз компетенциясенә керә торган һәм расланган көн тәртибе нигезендә утырышта референдум комиссиясе тарафыннан карала торган теләсә кайсы мәсьәлә буенча тавыш бирүне уздырырга тиеш.

8. Референдум комиссиясенең референдум комиссиясе рәисен, рәис урынбасарын һәм секретарен сайлау турындагы, референдум әзерләүне һәм үткәрүне финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләре хакындагы, тавыш бирү йомгаклары яисә референдум нәтиҗәләре турындагы, референдумны узмаган яисә дөрес түгел дип тану турындагы, референдум комиссиясе карарын юкка чыгару хакындагы карарлары референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавышы белән кабул ителә.

9. Референдум комиссиясенең башка мәсьәләләр буенча карарлары референдум комиссиясенең шунда катнашучы хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

10. Референдум комиссиясе карарларын кабул иткәндә «хуплап» һәм «каршы» бирелгән тавышлар саны тигез булган очракта, референдум комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

11. Референдум комиссиясе карарына референдум комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала.

12. Референдум комиссиясенең комиссия тарафыннан кабул ителгән карар белән килешмәүче әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язма рәвештә белдерергә хокуклы, әлеге комиссия өч көннән дә соңга калмыйча, ә тавыш бирү көнендә һәм тавыш биргәннән соңгы көндә кичекмәстән карарга һәм аны беркетмәдә чагылдырырга, беркетмәгә кушымта итеп бирергә һәм комиссия рәисе аны югарырак референдум комиссиясенә җиткерергә тиеш.

<u>29 статья.</u> Референдум комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерү

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең һәм аның урындагы затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Татарстан Республикасы Югары судына шикаять бирелергә мөмкин.

2. Башка референдум комиссияләренең һәм аларның урындагы затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата юга-

рырак комиссиягә яисә район (шәһәр) судына шикаять бирелергә мөмкин. Югарырак комиссиягә алдан мөрәҗәгать итү судка мөрәҗәгать итү өчен мәҗбүри шарт булып тормый.

3. Гражданнарның референдумда катнашу хокукын бозучы карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) карата шикаятьләр белән референдумда катнашучылар, җәмәгать берләшмәләре, инициатив төркемнәр, күзәтүчеләр, шулай ук референдум комиссияләре мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әгәр шикаятьтә (шикаятьләрдә) күрсәтелгән хокук бозулар гражданнарның күпчелек өлешенә кагылса йә башка сәбәпләр аркасында хокук бозу аеруча зур иҗтимагый әһәмияткә ия булса,Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе Россия Федерациясе Югары судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы, ул исә шикаятьнең асылын карарга тиеш.

4. Югарырак референдум комиссиясе, түбәнгерәк комиссиянең карарын юкка чыгарып, шикаятьнең асылы буенча мөстәкыйль карар кабул итәргә хокуклы.

5. Шикаятьләр һәм референдум комиссиясенә шуңа охшаш шикаять белән килгән гражданның мөрәҗәгате суд тарафыннан карауга алынган очракта, референдум комиссиясе, суд карары закон олы көченә кергәнче, шикаятьне карауны туктатып тора. Суд алынган шикаять турында комиссиягә хәбәр итә.

6. Судка алынган шикаятьләр суд тарафыннан федераль законда билгеләнгән вакытларда карала.

7. Референдумга әзерләнү барышында алынган шикаятьләр буенча карарлар федераль закон нигезендә биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көне алдыннан да соң түгел, ә тавыш бирү көнендә яисә тавыш бирүдән соңгы көндә кичекмәстән кабул ителә. Шикаятьләрдәге фактлар өстәмә тикшерүне таләп иткән очракта, алар буенча карарлар ун көннән дә соңга калмыйча кабул ителә. Референдумда тавыш бирү йомгаклары турында, референдум нәтиҗәләре турында комиссия карарына шикаять буенча суд шикаять белдерелгән көннән ике айдан да соңга калмыйча федераль закон нигезендә карар кабул итәргә тиеш.

8. Тиешле комиссияләр өчен суд карарларын үтәү мәҗбүри.

287

## IV бүлек. Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу), референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү, референдум участокларын төзү

30 статья. Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу)

1. Референдумда катнашу хокукына ия булган барлык гражданнар теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) өчен нигез - Татарстан Республикасы территориясендә гражданның даими яисә күбесенчә яшәү факты, ул халыкны теркәп исәпкә алу органнары тарафыннан федераль закон нигезендә билгеләнә.

3. Референдумда катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) җирле үзидарә башлыгы (әгәр җирле үзидарә уставында мондый эш урыны каралмаган булса - җирле үзидарә органы вәкаләт тапшырган зат), хәрби часть командиры тарафыннан һәр елның 1 гыйнварына һәм 1 июленә булган халәтендә башкарыла. Бу очракта дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы файдаланырга мөмкин.

4. Референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда) һәм референдумда катнашу өчен теркәлгәннәр турындагы белешмәләрне төгәлләштергәндә җирле администрацияләрнең башлыклары җирле үзидарә органнарына һәм референдум комиссияләренә кирәкле ярдәм күрсәтергә тиеш.

5. Референдумда катнашучы үзе турындагы документлаштырылган мәгълүмат (персональ белешмәләр) белән шул исәптән машина саклагычларындагылар белән дә, каршылыксыз танышырга, әлеге мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук әлеге мәгълүматны кем һәм нинди максатларда файдалануны һәм файдаланганын белергә хокуклы.

31 статья. Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү

1. Референдумда катнашучылар исемлекләрен референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан фай-

 288

даланып алынган һәм әлеге статьяның 4 пункты нигезендә тапшырылучы күрсәткечләр буенча территория комиссияләре төзи.

2. Тавыш бирү көненә референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнар референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелә.

3. Гражданны референдумда катнашучылар исемлегенә кертү өчен аның федераль законнар нигезендә билгеләнә торган шушы референдум участогы территориясендә даими яисә күбесенчә яшәү факты нигез була.

4. Референдумда катнашу өчен теркәлгәннәр турындагы белешмәләрне булдыру һәм төгәлләштерү җирле үзидарә башлыгы тарафыннан башкарыла, ә референдумда катнашучы хәрби частьтәге хәрби хезмәткәрләргә, аларның гаилә әгъзаларына һәм референдумда башка катнашучыларга карата, әгәр алар хәрби часть урнашкан территориядә яшәсәләр, хәрби часть командиры тарафыннан башкарыла. Күрсәтелгән мәгълүмат территория комиссияләре төзелгәч үк әлеге комиссияләргә җибәрелә. Референдумда катнашучыларның исемлеге һәр референдум участогы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвештә референдумда катнашучылар исемлеге төзелә.

5. Хәрби частьтән читтә яшәүче хәрби хезмәткәрләр яшәү урыны буенча референдумда катнашучылар исемлегенә гомуми нигезләрдә кертеләләр.

6. Тавыш бирү көнендә шифаханәләрдә, профилакторийларда, ял йортларында, хастаханәләрдә, бүтән стационар дәвалау-профилактикалау учреждениеләрендә һәм башка вакытлыча тору урыннарында референдумда катнашучылар исемлекләре шушы учреждениеләрнең җитәкчеләре бирә торган күрсәткечләр нигезендә аларның тору урыны буенча төзелә.

7. Көндез укып, тулай торакларда яшәүче студентлар һәм аспирантлар референдумда катнашучыларның тулай торак урнашкан урындагы исемлегенә кертеләләр.

8. Референдумда катнашучы бары тик бер генә участокта референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин.

9. Референдумда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Референдумда катнашучылар исемлегенә кертелүче референдумда катнашучылар турындагы мәгълүмат алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (референдумда катнашучыларның торак пунктлары, урамнары,

289

йортлары, адреслары буенча) урнаштырыла. Исемлектә референдумда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае) һәм даими яисә күбесенчә яшәү урынының адресы күрсәтелә. Референдумда катнашучылар исемлегенә - территория комиссиясе рәисе һәм секретаре, ә күрсәтелгән исемлекне участок комиссиясенә тапшырганнан соң участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә төзелгән референдум участокларындагы референдумда катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Референдумда катнашучылар исемлеге тиешле территория һәм участок комиссияләренең мөһерләре белән раслана.

10. Тиешле территория комиссиясе участок комиссияләренә конкрет референдум участогының референдумда катнашучыларының исемлеген тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча акт буенча тапшыра.

11. Участок комиссиясе референдум комиссиясе белән җирле үзидарә органнарының, референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) гамәлгә ашыручы учреждениеләрнең һәм оешмаларның үзара эшчәнлеген оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә референдумда катнашучылар исемлеген төгәлләштерә.

12. Референдумда катнашучылар исемлеге тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча референдумда катнашучыларны таныштыру һәм өстәмә төгәлләштерү өчен участок комиссиясе тарафыннан бирелә.

13. Референдумда катнашучылар исемлеген референдумда катнашучыларны таныштыру өчен тапшырганнан соң референдум участогы территориясенә килеп урнашкан референдумда катнашучылар, шулай ук теге яисә бу сәбәпләр аркасында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелми калган референдумда катнашучылар паспорт яисә аны алыштыручы документ, ә кирәк чакта аның шушы референдум участогы территориясендә даими яисә күбесенчә яшәү фактын раслаучы документлар нигезендә өстәмә рәвештә участок комиссиясе тарафыннан референдумда катнашучылар исемлегенә кертеләләр.

14. Референдумда катнашу хокукына ия граждан үзен референдумда катнашучылар исемлегенә кертмәү турында, шулай ук референдумда катнашучылар исемлегендәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турында участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Участок комиссиясе 24

290

сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә - мөрәҗәгать иткәннән соң 2 сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәгәлләнү мизгеленнән дә соңга калмыйча , гаризаны, шулай ук тапшырылган документларны тикшерергә тиеш һәм хатаны яисә тәгәлсезлекне бетерергә йә мөрәҗәгать итүчегә, гаризаны кире кагу сәбәпләрен бәян итеп, язмача җавап бирергә тиеш. Референдумда катнашучылар исемлегенә территория комиссиясе рәисе һәм секретаре имза салганнан соң гражданны референдумда катнашучылар исемлегеннән төшереп калдыру бары тик референдумда катнашучыларны теркәүне (исәпкә алуны) гамәлгә ашыручы тиешле органнардан алынган мәгълүмат нигезендә генә башкарыла. Мондый чакта референдумда катнашучылар исемлегендә гражданны исемлектән төшереп калдыру датасы һәм анык сәбәбе күрсәтелә. Әлеге язма участок комиссиясе рәисенең имзасы белән раслана. Участок комиссиясенең карарына карата референдумның югарырак комиссиясенә яисә судка шикаять бирелергә мөмкин, алар шикаятьне (гаризаны) - өч көн эчендә, ә тавыш бирү көнендә кичекмәстән карарга тиеш.

15. Тавыш бирү тәгәлләнгәннән соң һәм референдумда катнашучылар тавышларын санау башлангач, референдумда катнашучылар исемлегенә үзгәрешләр кертү тыела.

<u>32 статья.</u> Референдум участокларын төзү

1. Тавыш бирүне уздыру һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау өчен референдум участоклары төзелә.

2. Референдум участоклары, тиешле территория комиссиясе белән килешенеп, тавыш бирү көненә кадәр кимендә 30 көн кала, җирле үзидарә башлыгы тарафыннан (җирле үзидарә орагнннары булмаганда - җирле хакимият башлыгы тарафыннан) һәр сайлау участогында референдумда катнашучыларның саны 3 меңнән дә артмаслык итеп, әлеге Законның 30 статьясындагы 3 пункты нигезендә референдум участогы территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар саны турындагы белешмәләр буенча төзелә.

3. Референдумда катнашучыларның вакытлыча тору урыннарында (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында һәм бүтән вакытлыча

булу урыннарында) референдум участоклары - әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән вакытта, ә аерым очракларда - тавыш бирү көненә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

4. Хәрби хезмәткәрләр референдумның гомуми участокларында тавыш бирәләр. Искәрмә рәвешендә торак пунктларыннан аерым торган, ерак районнарда урнашкан хәрби частьләр территорияләрендә референдум участокларын төзү рөхсәт ителә. Бу очракларда референдум участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән чорда, ә аерым очракларда тавыш бирергә 5 көннән дә соңга калмыйча хәрби частьләрнең командирлары тарафыннан төзелә. Бу очракта референдумның участок һәм югарырак комиссияләренең барлык әгъзаларына, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затларга, шулай ук күзәтүчеләргә участок комиссиясе эшли торган бинага һәм тавыш бирү бинасына керү тәэмин ителергә тиеш.

5. Участок комиссияләренең һәм тавыш бирү биналарының чикләре, номерлары, урнашкан җирләре һәм телефон номерлары күрсәтелгән килеш, референдум участокларының һәм тавыш бирү биналарының исемлекләре, тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча, җирле үзидарә башлыгы тарафыннан (ул булмаганда - җирле администрация башлыгы тарафыннан) бастырып чыгарылырга тиеш.

## V бүлек. Референдум үткәргәндә үгетләү

<u>33 статья.</u> Үгетләү хокукы

1. Дәүләт гражданнарга, иҗтимагый берләшмәләргә, сәяси партияләргә референдум үткәргәндә закон нигезендә ирекле үгетләүне тәэмин итә.

2. Гражданнар, җәмәгать берләшмәләре, сәяси партияләр законда рөхсәт ителгән рәвешләрдә һәм законлы ысуллар белән референдум үткәрүне яклап яисә аны үткәрүгә каршы, референдумда катнашуны яклап яисә анда катнашуга каршы, референдумга чыгарылучы сорауларны яклап яисә аларга каршы үгетләүгә хокуклы.

292

3. Үгетләү түбәндәгечә алып барылырга мөмкин:

а) массакүләм мәгълүмат чаралары аша;

б) массакүләм гамәлләр (гражданнар белән җыелышлар һәм очрашулар, гавами дебатлар һәм дискуссияләр, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре) үткәрү юлы белән;

в) басма үгетләү материалларын бастырып чыгару һәм тарату юлы белән;

г) закон тарафыннан тыелмаган башка рәвешләрдә.

4. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз үгетләвенең рәвешен һәм характерын мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

5. Референдум үткәргәндә үгетләүдә түбәндәгеләр катнаша алмыйлар:

а) Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары;

б) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары;

в) үзләренең эш яисә хезмәт вазыйфаларын башкарганда яки эш яисә хезмәт урыннарындагы өстенлекләрдән файдаланып дәүләт эш урыннарын һәм җирле үзидарә эш урыннарын өстәмә эш буларак биләүче затларга, дәүләт хезмәткәрләре һәм җирле үзидарә хезмәткәрләре, хәрби хезмәткәрләр;

г) хәйрия оешмалары һәм дини берләшмәләр.

6. Референдумга бәйле иҗтимагый фикерне сорашып белү нәтиҗәләрен бастырып чыгарганда, массакүләм мәгълүмат чаралары сорашып белүне уздыручы оешманы,аны уздыру вакытын,сорашып белешенүчеләр санын (аралап алып), мәгълүмат җыю ысулын, сорауның төгәл формулировкасын, мөмкин булган ялгышларның статистик бәяләнешен күрсәтергә тиеш.

<u>34 статья.</u> Үгетләү чорлары

1. Референдум үткәргәндә үгетләү референдум билгеләү турындагы карар басылып чыккан көннән башлана һәм тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала ноль сәгатьтә туктатыла.

2. Референдум комиссияләре биналарыннан һәм йортларыннан читтә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә элегрәк эленгән басма үгетләү материаллары тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда саклана.

3. Тавыш бирү көненә кадәр өч көн дәвамында, шулай ук тавыш бирү көнендә җәмәгать фикерен сораштыруларның нәтиҗәләрен, референдум нәтиҗәләре фаразларын, референдумга бәйле башка төрле тикшеренүләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруга юл куелмый.

35 статья. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдалануның гомуми шартлары

1. Гамәлгә куючылары (гамәлдә куюда катнашучылары) дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары, оешмалары, учреждениеләре булган теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре (вакытлы матбугат басмалары) һәм (яисә) теле- һәм (яисә) радиотапшыруны гамәлгә ашыручы тиешле оешма бюджетыннан кимендә 15 проценты финансланучылар оешмалар, вакытлы матбугат басмасы редакцияләре референдум билгеләү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару көненә кадәрге ел өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә үгетләү өчен шартлар тәэмин итәргә тиеш. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы күрсәтелгән оешмалар һәм вакытлы матбугат басмасы редакцияләре исемлеге Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә дәүләт сәясәтен әзерләүче һәм башкаручы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан референдумда тавыш бирү көнен билгеләгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла. Бу исемлектә атнага бер мәртәбәдән дә сирәгрәк чыгарылучы вакытлы матбугат басмасы аерым билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 пункты кагылмаучы теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмасы редакцияләре референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә шартнамә нигезендә эфир вакытын, матбугат мәйданын бирергә

294

хокуклы. Эфир вакыты һәм матбугат мәйданы өчен түләү, шулай ук теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларның каналларында эфир вакытын бирү референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем тарафыннан референдумда катнашу өчен төзелгән тиешле фонд аша гына эфир вакытын һәм басма мәйданны биргәнче тулы күләмдә башкарылырга тиеш.

3. Эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләүнең күләме һәм шартлары турындагы мәгълүмат теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы тиешле оешма, вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан референдум үткәрү көнен билгеләгәч ун көннән дә соңга калмыйча үгетләү өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүгә әзерлек турындагы хәбәр белән бергә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Бу статьяның 1 пункты кагылмаучы, әлеге шартны үтәмәүче теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмасы редакцияләре, референдум үткәргәндә үгетләү максатында эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирергә хокуклы түгел.

4. Үгетләү максатында эфир вакыты һәм матбугат мәйданын түләүсез яисә түләүле бирүче теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре әлеге эфир вакыты һәм матбугат мәйданы күләменең һәм бәясенең аерым исәбен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган рәвешләр буенча алып барырга тиеш. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре әлеге исәпнең белешмәләрен тавыш бирү көненнән соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

<u>36 статья.</u> Массакүләм мәгълүматның электрон чаралары аша үгеләү шартлары

1. Референдум үткәрү инициаторы әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларның каналларында эфир вакытын түләүсез алырга хокуклы. Күрсәтелгән эфир вакыты теле- һәм радиопрограммалар аеруча зур

294

хокуклы. Эфир вакыты һәм матбугат мәйданы өчен түләү, шулай ук теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларның каналларында эфир вакытын бирү референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем тарафыннан референдумда катнашу өчен төзелгән тиешле фонд аша гына эфир вакытын һәм басма мәйданны биргәнче тулы күләмдә башкарылырга тиеш.

3. Эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләүнең күләме һәм шартлары турындагы мәгълүмат теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы тиешле оешма, вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан референдум үткәрү көнен билгеләгәч ун көннән дә соңга калмыйча үгетләү өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүгә әзерлек турындагы хәбәр белән бергә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Бу статьяның 1 пункты кагылмаучы, әлеге шартны үтәмәүче теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмасы редакцияләре, референдум үткәргәндә үгетләү максатында эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирергә хокуклы түгел.

4. Үгетләү максатында эфир вакыты һәм матбугат мәйданын түләүсез яисә түләүле бирүче теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре әлеге эфир вакыты һәм матбугат мәйданы күләменең һәм бәясенең аерым исәбен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган рәвешләр буенча алып барырга тиеш. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре әлеге исәпнең белешмәләрен тавыш бирү көненнән соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

<u>36 статья.</u> Массакүләм мәгълүматның электрон чаралары аша үгеләү шартлары

1. Референдум үткәрү инициаторы әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларның каналларында эфир вакытын түләүсез алырга хокуклы. Күрсәтелгән эфир вакыты теле- һәм радиопрограммалар аеруча зур

аудитория җыйган чакка туры килергә тиеш. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы һәр оешма үгетләү өчен бүлеп биргән түләүсез эфир вакытының гомуми күләме эш көннәрендә кимендә 30 минут булырга, әгәр теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешманың гомуми тапшыру вакыты бер көнгә ике сәгатьтән дә ким булса - тапшыру вакытының гомуми күләменең кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш. Түләүсез үгетләү материалларының эфир вакыты Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе һәм тиешле территория комиссиясе тарафыннан, теле- һәм (яисә) радиотапшырулар ны гамәлгә ашыручы оешмаларның вәкилләре, референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем, катнашында билгеләнә.

2. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар үгетләү өчен түләүле эфир вакытын резервта тотарга тиеш. Күрсәтелгән эфир вакыты шартнамә шартларында референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә түләүле рәвештә алар таләбе буенча бирелергә тиеш. Түләү күләме референдумда тавыш бирү көне билгеләнгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга тиеш. Резервта тотылучы эфир вакытының гомуми күләме әлеге статьяның 1 пункты нигезендә бирелүче түләүсез эфир вакытының гомуми күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар каналларында эфир вакытын референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә бүлеп бирү тәртибе әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә дәүләт хакимиятенең дәүләт сәясәтен эшләүче һәм гамәлгә ашыручы башкарма органнары белән килешенеп билгеләнә.

4. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларның референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, референдум комиссияләренә түләүсез эфир вакытын бирүгә бәйле чыгымнар теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмаларны агымдагы бюджет финанславы акчалары исәбеннән каплана.

37 статья. Массакүләм мәгълүматның басма чаралары аша үгетләү шартлары

1. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә таралучы вакытлы матбугат басмаларының редакцияләре, боларга бары тик рәсми хәбәрләр һәм материаллар, норматив һәм бүтән төрле актлар бастырып чыгару өчен генә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре (вакытлы матбугат басмалары) керми, референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә материаллар бастыру өчен матбугат мәйданнары бүлеп бирергә тиеш. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы вакытлы матбугат басмалары редакцияләре референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә бүлеп бирелә торган матбугат мәйданының гомуми атналык минималь күләме тиешле басманың атналык матбугат мәйданы гомуми күләменең кимендә 5 процентын тәшкил итәргә тиеш. Бу очракта бүленеп бирелүче гомуми матбугат мәйданының кимендә 40 проценты әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пункты кагылучы вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан аларның агымдагы бюджет финанславы акчалары исәбеннән түләүсез бүлеп бирелә.

2. Вакытлы матбугат басмалары редакцияләре (вакытлы матбугат басмалары) тарафыннан матбугат мәйданнарын референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә түләүле рәвештә бирү шартнамә шартларында башкарыла. Массакүләм мәгълүматның басма чаралары билгеләгән түләү күләме һәм шартлары турындагы мәгълүматы референдумда тавыш бирү көне билгеләнгәч 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыга.

3. Вакытлы матбугат басмаларында референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә матбугат мәйданын бирү тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә дәүләт хакимиятенең дәүләт сәясәтен эшләүче һәм гамәлгә ашыручы башкарма органы белән килешеп билгеләнә.

4. Вакытлы матбугат басмаларында урнаштырылучы һәм референдумда катнашу фонды акчаларыннан түләнүче барлык материалларда түләүнең референдумда катнашу фондыннан башкарылуы турында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш. Әгәр материалларны бастыру әлеге статьяның 1 пунктында бәян ителгән нормалар нигезендә түләүсез һәм (яисә) референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем материалларын бастырып чыгару өчен матбугат мәйданын түләүсез бирү турындагы башка нормалар нигезендә башкарылса, басма материалда әлеге публикациянең түләүсез урнаштырылуы күрсәтелергә тиеш.

<u>38 статья.</u> Массакүләм гамәлләр үткәрү юлы белән үгетләү уздыру шартлары

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә гражданнар белән җыелышлар, очрашулар, гавами дебатлар һәм дискуссияләр, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре оештыруга ярдәм итәргә, массакүләм гамәлләр уздырганда иминлек тәэмин итәргә тиеш. Шушы максатлар өчен Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасының аеруча кыйммәт объектларының дәүләт җыелмасына кертелгән биналарны һәм корылмаларны бирү тыела.

2. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем һәм аларның вәкилләренең очрашуларын, референдумга чыгарылучы сораулар буенча фикер алышулар өчен гражданнарның җыелышларын уздырырга бина биреп тору турындагы гаризалар шулар бирелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан каралырга тиеш. Митинглар, демонстрацияләр һәм урам йөрешләре оештыручыларның заявкалары Россия Федерациясе законнары нигезендә карала.

3. Референдум комиссияләре заявка буенча массакүләм гамәлләр уздыруга яраклы һәм дәүләт милкендәге яисә җирле үзидарә милкендәге биналар референдум комиссиясе билгеләгән вакытка референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем һәм аларның вәкилләре белән

референдумда катнашучылар очрашуларын уздыру өчен файдаланугa түләүсез биреләләр.

<u>39 статья.</u> Басма үгетләү материалларын, аудиовизуаль материалларны һәм бүтән төрле материалларны тарату шартлары

1. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем басма үгетләү материалларын, шулай ук аудиовизуаль һәм бүтән төрле үгетләү материалларын бастырып чыгарырга хокуклы.

2. Барлык басма үгетләү һәм, аудиовизуаль материалларда басма материалларны әзерләгән оешмаларның исемнәре һәм адреслары (затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, яшәү урыннары), басма материалларга заказ биргән оешманың исеме (затның фамилиясе, исеме, атасының исеме), шулай ук аларның тиражы һәм бастырып чыгару датасы турында мәгълүмат булырга тиеш.

3. Басма үгетләү һәм аудиовизуаль материалларның нөсхәләре яисә аларның күчермәләре, таратыла башланганчыга кадәр, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән материаллар белән бергә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә шулай ук әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешмаларның (затларның) урнашкан урыны турында (яшәү урынындагы адресы турында) мәгълүмат тапшырылырга тиеш. Басма үгетләү, аудиовизуаль материалларны референдум үткәрү инициаторының, инициатив төркемнең язма рәвештәге ризалыгыннан башка әзерләүгә һәм таратуга юл куелмый.

4. Басма, үгетләү материалларын әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән таләпләрне бозып тарату тыела.

5. Басма үгетләү материаллары биналар эчендә, йортларга, корылмаларга һәм башка объектларга күрсәтелгән объектлар милекчеләренең яисә биләүчеләренең ризалыгы белән эленергә мөмкин. Күрсәтелгән материалларны һәйкәлләргә, обелискларга һәм тарихи, мәдәни яисә архитектура кыйммәте булган биналарга, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум комиссияләре биналары эчендә, аларга керү урыннарына һәм тавыш бирү биналары эчендә элү тыела.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә референдум комиссиясе тәкъдиме буенча тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча һәр референдум участогы территориясендә басма үгетләү материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар булдырырга тиеш.

7. Ялган басма, аудиовизуаль үгетләү материалларын тарату турында яисә басма, аудиовизуаль үгетләү материалларын әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматсыз тарату турында хәбәр алган Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе әлеге эшчәнлекне туктату буенча чаралар күрә һәм хокукка каршы үгетләү эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә белән һәм, законсыз басма үгетләү материалларын тартып алуны сорап, хокук саклау органнарына, бүтән органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**40 статья.** Референдумда катнашучыларның референдумга чыгарылучы закон проекты тексты белән үз вакытында танышу хокукы гарантияләре

Референдумга Татарстан Республикасы закон проекты чыгарылган очракта референдумда һәр катнашучы тавыш бирү көненә кимендә 30 көн кала җирле үзидарә органында әлеге проект текстын алырга хокуклы. Мондый текстны әзерләү һәм тарату бурычы референдум үткәрү инициаторына, инициатив төркемгә йөкләнә.

**41 статья.** Үгетләү хокукыннан явыз ниятләрдә файдалануга юл куелмау

1. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, референдум комиссияләре референдум үткәргәндә үгетләүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тота.

2. Үгетләгәндә түбәндәге очракларда ирекле массакүләм мәгълүматтан явыз ниятләрдә файдалануга юл куелмый: социаль, раса, милли, дини нәфрәтне һәм дошманлыкны уятучы үгетләү, хакимиятне басып алуга, конституциячел корылышны көч кулланып үзгәртүгә һәм дәүләтнең бөтенлеген

300

җимерүгә өндәү, сугышны пропагандалау һәм ирекле массакүләм мәгълүмат чараларыннан явыз нияттә файдаланунын федераль законнар белән тыелган башка төрле рәвешләре.

3. Референдум үткәрү иництаторларынын, инициатив төркемнең, һәм аларның вәкаләтле вәкилләренең, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча үгетләүдә турыдан-туры яисә читләтеп катнашучы бүтән оешмаларның һәм затларның референдумда катнашучыларны түбәндәгечә сатып алулары тыела: аларга акча, бүләкләр һәм, үтәлгән оештыру эше өчен (референдум участокларында кизү тору, имзалар җыю, үгетләү эше алып бару) түләүдән гайре, башка төрле матди кыйммәтләр өләшү, күрсәтелгән оештыру эшен башкарган референдумда катнашучыларны тавыш бирү йомгакларына карап бүләкләү, басма товарлардан гайре, товарларны ташламалы бәяләргә сату, теләсә нинди товарлар (шул исәптән иллюстратив, референдум әзерләү һәм үткәрү өчен махсус әзерләнгән материаллар һәм значоклар) тарату, шулай ук бушлай яисә ташламалы шартларда хезмәт күрсәтүләр. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем һәм аларның вәкаләтле вәкилләре, бүтән затлар һәм оешмалар үгетләү уздырганда референдумда катнашучыларга акча, кыйммәтле кәгазьләр һәм башка матди байлыклар бирүне вәгъдә итеп (шул исәптән тавыш бирү йомгаклары буенча), шулай ук законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары кабул иткән карарлардагыдан бүтәнчә хезмәт күрсәтеп, йогынты ясарга хокуклы түгел.

4. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем әгъзалары һәм вәкаләтле вәкилләре, шулай ук күрсәтелгән затлар һәм оешмалар гамәлгә куючылары, милекчекләре, биләүчеләре һәм (яисә) җитәкче органнарының әгъзалары булып торган оешмалар, шулай ук күрсәтелгән затлар һәм оешмалар үтенече яисә кушуы буенча эш итүче башка физик һәм юридик затлар референдум үткәргәндә хәйрия эшчәнлеге белән шөгыльләнмәскә тиеш. Күрсәтелгән затларның һәм оешмаларның референдумда катнашучыларга һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларга матди һәм финанс ярдәме яисә хезмәт күрсәтүләр турындагы тәгъдимнәр белән башка физик һәм юридик затларга мөрәҗәгать итүләре тыела. Физик һәм юридик затларга референдум үткәрү инициаторы,

инициатив төркем, аларның вәкаләтле вәкилләре һәм ышанычлы затлары исеменнән яисә аларны хуплап, хәйрия эшчәнлеге башкару тыела.

5. Референдум үткәрү иництаторының, инициатив төркем әгъзаларының һәм вәкаләтле вәкилләренең, шулай ук күрсәтелгән затлар һәм оешмалар гамәлгә куючылары, милекчеләре,биләүчеләре һәм (яисә) җитәкче органнар әгъзалары булып торган оешмаларның коммерция һәм бүтән төрле эшчәнлеген референдум үткәргәндә рекламалау әлеге Законның 35 статьясындагы 2 пунктында һәм 37 статьясындагы 6 пунктында каралган нигезләрдә башкарыла. Тавыш бирү көнендә һәм тавыш бирү алды көнендә реклама рөхсәт ителми.

6. Референдум үткәрү иництаторы, инициатив төркем референдум мәсьәләләре буенча үгетләүнең әлеге Законның 33-41 статьяларында билгеләнгән бүтән кагыйдәләрен бозган очракта Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе инициатив төркемгә һәм җәмәгать берләшмәсенә үз карары аша кисәтү ясый йә хокукка каршы үгетләү эшчәнлеген туктату турындагы тәкъдим белән хокук саклау органнарына һәм башка органнарга мөрәҗәгать итә. Референдум комиссиясенең тиешле карары массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

7. Хокук саклау органнары хокукка каршы үгетләү эшчәнлеген туктату, ялган һәм законсыз басма, аудиовизуаль һәм башка төрле үгетләү материалларын әзерләүне булдырмый калу һәм аларны тартып алу чараларын күрергә, күрсәтелгән материалларны әзерләүчеләрне һәм шулар өчен түләү чыганакларын билгеләргә, шулай ук ачылган фактлар һәм күрелгән чаралар турында Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә һәм тиешле референдум комиссиясенә хәбәр итәргә тиеш.

8. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар, вакытлы матбугат басмалары редакцияләре үгетләүнең әлеге Законда билгеләнгән кагыйдәләрен бозган очракта, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, референдум комиссиясе хокукка каршы гамәлне туктату һәм теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыру оешмасын, вакытлы матбугат басмасы редакциясен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тарту турындагы тәкъдим белән хокук саклау органнарына, судка, дәүләт хакимиятенең массакүләм мәгълүмат чаралары

өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы башкарма органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## VI бүлек. Референдумны финанслау

### 42 статья. Референдум әзерләүне һәм үткәрүне финанс ягыннан тәэмин итү

1. Референдумны әзерләүгә һәм үткәрергә бәйле чыгымнар, Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнә. Әлеге Законның гамәлдә булуы референдум комиссияләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеген финанслау өлешендә референдумны финанслауга кагыла.

2. Референдум комиссияләре чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджетында аерым юл рәвешендә карала.

3. Референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә акчалар бүлеп бирү турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан референдум билгеләү турындагы карар белән бер үк вакытта кабул ителә.

4. Референдум әзерләү һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасының республика бюджетында каралган акчалар референдум көнен билгеләгәннән соң ун көн эчендә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе карамагына тапшырыла һәм ул аны референдум комиссияләренә бүлеп бирә.

5. Әгәр референдумны финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылмаса, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе акчалары вакытында күчерелмәсә, әлеге чыгымнар банк кредитлары исәбеннән түләнә, алар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан конкурс нигезендә тәкъдим ителә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мөрәҗәгать иткәннән соң 10 көн эчендә аңа кредит акчаларын кайтару йөкләмәләрен, аңа карата исәпләнә торган процентларны да кертеп, үтәүне дәүләт ягыннан гарантияли.

6. Кредит акчаларыннан файдаланган өчен исәпләнелә торган әлеге кредит акчаларын һәм процент түләүләрен кире кайтару Татарстан Респуб-

ликасының республика бюджеты акчаларыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге бурыч йөкләмәләрен бетерү өчен акча чираттагы финанс елына максатчан билгеләнеш буенча Татарстан Республикасының бюджет системасы турындагы закон белән раслана.

7. Референдум участок комиссиясе референдум территория комиссиясенә Татарстан Республикасы республика бюджетының әлеге участок комиссиясе тарафыннан референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчаларының керүе һәм тотылуы турында тавыш бирү көненнән соң 10 көннән дә соңга калмыйча финанс хисабы бирә. Территория комиссиясе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы республика бюджетының әлеге территория комиссиясенә референдум үткәрүгә һәм әзерләүгә бүлеп бирелгән акчаларының керүе һәм тотылуы турында тавыш бирү көненнән соң 20 көннән дә соңга калмыйча финанс хисабы бирә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы республика бюджетының референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчаларының керүе һәм тотылу турында референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыканнан соң 3 айдан да соңга калмыйча финанс хисабы бирә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе, референдум комиссияләренең рәисләре референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар белән эш итәләр һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, референдум комиссияләренең финанс мәсьәләләре хакындагы карарларына финанс документларының туры килү-килмәве һәм күрсәтелгән акчаларны тоту турында финанс хисаплары бирү буенча җаваплы булалар.

8. Референдум комиссияләренә счетлар ачу һәм алып бару, исәпкә алу, хисаплылык һәм бүлеп бирелгән акчаны күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешенеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, референдум комиссияләренең счетлар ачу буенча банк тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләр өчен һәм счетлар буенча гамәлләр үздырган өчен түләү алынмый. Күрсәтелгән счетлардагы акчалардан файдаланган өчен банк тарафыннан процентлар түләнми.

504

43 статья. Референдумда катнашу фонды, аны төзү һәм шушы фондтагы акчаларны тоту тәртибе

1. Референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем референдум үткәрү инициативасын гамәлгә ашыру һәм референдум мәсьәләләре буена үгетләү эшчәнлеген финанслау өчен үзенең референдумда катнашу фондын төзергә тиеш.

2. Референдумда катнашу фондын тәшкил итүче акчалар Россия Федерациясе Саклык банкының «Татарстан» банкы бүлегендәге махсус счетка күчерелә. Әгәр референдум үткәрү инициативасы гражданнарга һәм җәмәгать берләшмәләренә караса, ә референдум үткәрү инициаторы Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы халык депутатлары булса, референдум билгеләү турында карар кабул ителгәч әлеге счет Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә имзалар җыю турындагы язма хәбәрне җибәргәннән соң Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рөхсәте белән ачыла.

3. Күрсәтелгән счетны ачу һәм алып бару тәртибе, фонд акчаларын исәпкә алу һәм хисаплылык тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килешенеп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Фонд акчаларын күрсәтелгән максатларда тоту хокукы шушы фондны төзегән референдум үткәрү иництаторына, инициатив төркемгә бирелә.

5. Референдумда катнашу фонды түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

референдум үткәрү иництаторының, инициатив төркем әгъзаларының үз акчалары, ул акчаларның барлык суммасы җыелмасы референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән 150 минималь күләменнән артмаска тиеш;

референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә гражданнарның һәм юридик затларның хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән 30 минималь күләменнән һәм һәр юридик зат өчен 3 мең тапкырдан артмаган ихтыярый иганәләре.

6. Референдумда катнашу фонды акчалары исәбеннән чыгымнарының иң чик суммасы референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә хезмәт өчен түләүнең Татарстан Республикасында билгеләнгән 20 мең минималь күләменнән дә артмаска тиеш.

7. Референдумда катнашу фондларына түбәндәгеләрдән иганә алу рөхсәт ителми:

Россия Федерациясенең 18 яше тулмаган гражданнарыннан;

чит илләрдән, чит ил юридик затларыннан һәм гражданнарыннан;

гражданлыксыз затлардан;

әгәр референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә чит ил капиталы өлеше аларның устав (җыелма) капиталында 30 проценттан артып китсә, чит ил катнашындагы Россия юридик затларыннан;

халыкара оешмалардан һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләрдән;

әгәр референдум билгеләү турыдагы карар рәсми басылып чыккан көнгә устав (җыелма) капиталында 30% тан артыгы дәүләт өлеше яисә җирле үзидарә өлеше булса, юридик затлардан;

табыш бирү көненә кадәр бер елдан азрак вакытта теркәлгән юридик затлардан;

дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан, җирле үзидарә учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан;

хәрби частьләрдән, хәрби учреждениеләрдән һәм оешмалардан, хокук саклау органнарыннан;

аноним иганәчеләрдән (гражданнар өчен - түбәндәге белешмәләрнең теләсә кайсын күрсәтмичә: фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урыны адресын һәм туган көнен; юридик затлар өчен - түбәндәге белешмәләрнең теләсә кайсын күрсәтмичә: салым түләүченең идентификация номерын, исемен, теркәү көнен, банк реквизитларын, устав (җыелма) капиталында дәүләт өлешенең яисә җирле үзидарә өлешенең юклыгы яисә, андый өлешнең күләмен күрсәтеп, барлыгы турында, устав (җыелма) капиталында чит илнең катнашмавы хакында яисә, катнашу өлешен күрсәтеп, аның күләме турында).

306

8. Референдумга турыдан-туры яисә читләтеп бәйле булган эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне һәм товарлар сатуны юридик затлар, аларның филиаллары, вәкиллекләре һәм башка төрле бүлекчәләре тарафыннан түләүсез башкару яисә нигезсез арзанайган бәяләргә башкару тыела. Референдумны әзерләү һәм үткәрү эшләрен, хезмәт күрсәтүләрне гражданның, өченче затларны җәлеп итмичә генә, үзе теләп бушлай шәхсән башкаруы рөхсәт ителә.

9. Референдумда катнашу фондының акчалары максатчан билгеләнешкә ия. Алар бары тик референдум үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауда гына файдаланыла алалар. Фондларның акчалары түбәндәгеләргә файдаланылырга мөмкин:

а) референдумда катнашучыларның имзаларын җыюга юнәлдерелгән оештыру-техник чараларны финанс ягыннан тәэмин итүгә, шул исәптән референдумда катнашучыларның имзаларын җыю өчен җәлеп ителгән затларның хезмәтләре өчен түләүгә;

б) үгетләүгә, шулай ук мәгълүмати һәм консультацион характердагы эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә;

в) юридик затлар яисә гражданнар тарафыннан башкарылган (күрсәтелгән) башка эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә, шулай ук референдум үткәрүгә турыдан-туры бәйле башка чыгымнарга.

10. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю, үгетләү, референдум үткәрүгә турыдан-туры бәйле башка гамәлләрне тормышка ашыру эшләренә түләү өчен референдум үткәрү инициаторының, инициатив төркемнең бүтән акчалардан файдалануы тыела, моңа аларның референдумда катнашу фондына алынган акчалары керми.

11. Референдумда катнашу фонды счетын тотучы банк Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе таләбе буенча даими рәвештә, әмма 10 көнгә бер тапкырдан да кимрәк түгел, аңа әлеге фонд счетындагы акчаларның керүе һәм тотылуы турында мәгълүмат бирергә тиеш.

12. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр референдумда катнашу фондына акчалар керү һәм тоту турындагы мәгълүматны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына даими рәвештә җибәреп тора. Әлеге Законның 35 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән массакүләм мәгълүмат чаралары

әлеге мәгълүмат алынган мизгелдән өч көн эчендә аны бастырып чыгарырга тиеш.

13. Референдумда катнашу фондын төзү өчен ачыла торган махсус счетлары буенча башкарылучы барлык финанс гамәлләре тавыш бирү көнендә туктатыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр башкарылган чыгымнарны түләү буенча финанс гамәлләрен башкару вакытын референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем үтенечнамәсе нигезендә озайта ала.

14. Махсус счеттагы тотылмаган акчаларның калган өлеше референдум үткәрү инициаторы, инициатив төркем иганә йә акча күчерүче оешмалар һәм затлар счетларына кертkән акчаларга тәңгәл рәвештә күчерелергә тиеш. Махсус счетта калган акчаларны банк тавыш бирү көненнән соң 60 көн узгач, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең язма күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасының республика бюджеты керемен҅ә күчерергә тиеш.

## VII бүлек. Тавыш бирүне оештыру һәм аның тәртибе, референдумда катнашучылар тавышларын санау референдум нәтиҗәләрен билгеләү һәм аларны бастырып чыгару

### 44 статья. Тавыш бирү бинасы

1. Тавыш бирү бинасы участок комиссиясе карамагына тиешле җирле администрация башлыгы тарафыннан түләүсез бирелә.

2. Тавыш бирү бинасында яшерен тавыш бирү өчен яктырту системасы куелган һәм язу әсбаплары (карандашлардан гайре) белән тәэмин ителгән кабиналары яисә махсус җиһазландырылган башка урыннары булган зал булырга тиеш.

3. Тавыш бирү бинасында яисә аның каршында ук участок комиссиясе стенд җиһазлый, анда референдумга чыгарылган мәсьәләләр турында мәгълүмати материаллар элена. Күрсәтелгән материалларда үгетләү өндәмәләре булмаска тиеш. Стендка комиссия референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең үрнәкләрен элә, аларда референдумга чыгарылган һәр

сорау буенча бюллетень тутыруның барлык вариантлары да күрсәтелергә тиеш.

4. Тавыш бирү бинасында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвеше булырга тиеш, ул тавыш бирү йомгаклары ачыкланган саен, шулар турындагы белешмәләрне теркәү өчен файдаланыла.

5. Тавыш бирү урыны референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре, тавыш бирү кабиналары һәм әрҗәләре участок комиссиясе әгъзаларының, күзәтүчеләр күз алдында булырлык итеп җиһазландырылырга тиеш.

45 статья. Референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы

1. Референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм референдум участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килү мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы тиешле территория комиссиясеннән (тавыш бирергә 44-25 көн кала) йә шушы референдум участогының участок комиссиясеннән (тавыш бирергә 24-1 көн кала) бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, Татарстан Республикасы чикләрендә тавыш бирү көнендә кайсы референдум участогында булса, шунда тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Референдумда тавыш бирү өчен бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы (алга таба - бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы) катгый хисап документы була, аның яклану дәрәҗәсен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели. Бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләү һәм бирү тәртибе, аларны бирү реестры саны һәм рәвеше, шулай ук аларны әзерләүгә карата куелучы таләпләр, тавыш бирү көненә 50 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары югарырак референдум комиссиясеннән түбәнгерәк комиссиягә референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен бирү тәртибендә тапшырылалар.

3. Тиешле референдум комиссиясе референдумда катнашучының бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын таләп итүенең

сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук референдумда катнашучы дәвалана торган стационар дәвалау-профилактика учреждениесе администрациясе тарафыннан да, шик белдерелүчеләрне яисә гаепләнүчеләрне сак астында тотучы учреждение администрациясе тарафыннан да таныкланырга мөмкин.

4. Территория комиссиясе референдумда катнашучыга йә аның вәкиленә җирле үзидарә башлыгы тарафыннан референдумда катнашучылар турында комиссиягә бирелгән мәгълүмат нигезендә бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын тапшыра. Территория комиссиясе бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрын төзи, аларда референдумда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Тавыш бирергә 25 көн кала референдум территория комиссиясе участок комиссиясенә, референдумда катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә, бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан расланган өземтәләрне җибәрә, аларда бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары алган һәм тиешле референдум участоклары территорияләрендә теркәлгән референдумда катнашучылар турында мәгълүмат күрсәтелә. Шундый өземтә нигезендә участок комиссиясе референдумда катнашучылар исемлегенә тиешле тамгаларны кертә.

5. Бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы алуы турында референдумда катнашучы яисә аның вәкиле бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына (территория комиссиясендә) йә референдумда катнашучылар исемлегенә (участок комиссиясендә) имза сала, анда аның паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры, алу датасы күрсәтелә. Бу чакта референдумда катнашучылар исемлегенә тиешле тамга салына һәм референдумда шушы катнашучы участок комиссиясенең беркетмәсен төзегәндә референдумда катнашу өчен теркәлгән затларның санын санаганда исәпкә алынмый.

310

6. Әгәр бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгында территория яисә участок комиссиясенең мөһере һәм бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын биргән территория яисә участок комиссиясе әгъзасының имзасы булса, мондый таныклык гамәлгә яраклы дип санала.

7. Бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын күрсәтеп, референдумда катнашучы теләсә кайсы башка референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелергә тиеш. Референдумда катнашучы бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы нигезендә тавыш бирү бюллетене алганда, референдумда катнашучылар исемлегендә үзе яшәгән урынның адресын күрсәтә.

8. Референдумда катнашучы бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгын референдумда катнашучылар исемлегенә элек кертелгән референдум участогында тавыш бирү көнендә күрсәткән очракта өстәмә рәвештә шул исемлеккә кертелә, ә бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы аннан алына һәм гамәлдән чыгарыла. Тиешле территория яисә участок комиссиясе бүтән референдум участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларын юкка чыгару турында актлар төзи.

<u>46 статья.</u> Референдумда тавыш бирү бюллетене

1. Референдум үткәрү өчен референдумда катнашучы референдумда тавыш бирү бюллетене ала.

2. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре бары тик Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча һәм күзәтүе астында гына эшләнә һәм алар катгый хисап документлары була. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең саны референдумда катнашучыларның теркәлгән саныннан 3 проценттан да артык булмаска тиеш.

3. Референдумда тавыш бирү бюллетененең рәвеше һәм тексты, шулай ук бюллетеньнәрне әзерләү тәртибе, аларның саны, бюллетеньнәр әзерләүгә таләпләр тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бюллетеньнең тексты аның бары тик бер ягына гына язылырга тиеш.

4. Референдумда тавыш бирү бюллетенендә референдумга чыгарылган сорауның тексты тәгәл итеп бирелә һәм «әйе» яисә «юк» сүзләре белән тавыш бирүченең ихтыярын белдерү вариантлары күрсәтелә, ул сүзләр астына буш квадратлар урнаштырыла. Референдумга берничә сорау, закон вариантлары (закон статьялары) чыгарылган очракта, алар бер референдумда тавыш бирү бюллетененә кертелергә мөмкин, мондый чакта закон вариантларына (закон статьяларына) бер-бер артлы номер куела һәм алар берсеннән-берсе горизонталь сызыклар белән аерылалар. Әгәр референдумга закон вариантлары (закон статьялары) чыгарылса, бюллетеньдә йә аның тексты бирелә, йә ул текстның мәгънәви асылы күрсәтелә, монда уң якка урнашкан буш квадрат турысына «барлык вариантларга каршы» юлы языла.

5. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре - Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, ә кирәк очракларда территорияләрдә оешкан төстә яши торган Россия Федерациясе халыклары телләрендә бастырыла. Әгәр референдум участогы өчен бюллетеньнәр ике һәм аннан күбрәк телләрдә басылса, рус телендәге текст референдумда тавыш бирү бюллетененең һәркайсында урнаштырылырга тиеш.

6. Типография референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен, бракларын сайлап алганнан соң,акт буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыра. Тиешле заказ санындагы бюллетеньнәрне тапшырганнан соң, типография хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары, инициатив төркем вәкилләре катнашында, референдумда тавыш бирүнең брак дип саналган һәм артып калган бюллетеньнәрен юкка чыгаралар, бу хакта акт төзелә, аңа барлык катнашучы затлар имза сала.

7. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, типографиядән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен алганнан соң, аларны акт буенча территория комиссияләренә тапшыра, алар шул ук тәртиптә бюллетеньнәрне турыдан-туры участок комиссияләренә тапшыралар.

8. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең дөрес тапшырылуы өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе, референдум комиссияләренең бюллетеньнәрне тапшыруны һәм алуны гамәлгә ашыручы рәисләре җаваплы була.

312

9. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре территория комиссияләренә - тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соң калмыйча, ә участок комиссияләренә тавыш бирү көненә кадәр 4 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

10. Акт буенча участок комиссиясенә тапшырылучы референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең саны референдумның югарырак комиссиясе карары белән билгеләнә. Участок комиссиясенә бирелүче бюллетеньнәрнең саны бюллетеньнәр тапшыру көненә референдум участогы буенча референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санынннан 0,5 проценттан да артыграк булмаска тиеш.

11. Референдумда тавыш бирү бюллетенененең өстәге уң як почмагына участок комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар участок комиссиясе мөһере белән раслана.

47 статья. Тавыш бирү тәртибе

1. Референдумда тавышы бирү 7 сәгатьтән алып 21 сәгатькә кадәр үткәрелә.

2. Тавыш бирү вакыты һәм урыны турында территория һәм участок комиссияләре, тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм бүтән юллар белән хәбәр итәргә тиешләр.

3. Референдумда катнашучыларның һәркайсы шәхсән үзе тавыш бирә, референдумда катнашучы башкалар өчен тавыш бирү рөхсәт ителми.

4. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларга паспорт яисә аны алыштыручы документ күрсәтелгәч, ә референдумда катнашучы бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргәндә, шулай ук бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелгәч бирелә.

5. Референдумда тавыш бирү бюллетенен алганда референдумда катнашучы референдумда катнашучылар исемлегендә үзенең паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясен һәм номерын куя. Референдумда катнашучының ризалыгы белән йә аның үтенече буенча

күрсәтелүче паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры референдумда катнашучылар исемлегенә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы тарафыннан кертелергә мөмкин. Референдумда катнашучы кертелгән язманың дөреслеген тикшерә һәм имза сала. Бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, референдумда катнашучылар исемлегендә өстәмә тамгалар ясала.

6. Тавыш бирү референдумда катнашучы тарафыннан референдумда тавыш бирү бюллетенендә, мәсьәләгә (мәсьәләләргә) карата ихтыярын белдереп, квадратта (квадратларда) теләсә нинди тамга кую юлы башкарыла.

7. Референдумда тавыш бирү бюллетене референдумда катнашучы тарафыннан махсус җиһазландырылган кабинада, башка затларның булуы рөхсәт ителми торган махсус җиһазландырылган бүтән урында тутырыла.

8. Референдумда катнашучы референдумда тавыш бирү бюллетенен тутырганда хата ясадым дип санаган очракта, ул, бозылганы урынына яңа бюллетень бирүне үтенеп, бюллетень биргән референдум комиссиясе әгъзасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Референдум комиссиясе әгъзасы референдумда катнашучыга референдумда тавыш бирүнең яңа бюллетенен бирә, мондый чакта референдумда катнашучылар исемлегендә референдумда әлеге катнашучының фамилиясе алдына тиешле тамга ясый. Бозылган бюллетень юк ителә, бу хакта акт төзелә.

9. Референдумда тавыш бирү бюллетененә мөстәкыйль рәвештә имза кую мөмкинлеге булмаган референдумда катнашучы моның өчен референдум комиссиясе әгъзасы, референдум үткәрү инициаторы, аның вәкаләтле вәкиле, инициатив төркем әгъзасы яисә аның вәкаләтле вәкиле, күзәтүче булмаган референдумда бүтән катнашучының ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый очракта референдумда катнашучы референдумда тавыш бирү бюллетенен тутыру өчен бүтән затның ярдәменнән файдаланырга нияте барлыгы турында референдум комиссиясенә телдән хәбәр итә. Бу очракта референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) референдумда катнашучыга ярдәм күрсәтүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме,

паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

10. Референдумда тавыш бирүнең тутырылган бюллетеньнәре референдумда катнашучы тарафыннан мөһерләнгән (пломбаланган) тавыш бирү әрҗәләренә төшерелә.

11. Референдум комиссиясе эшенә йә гражданның референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашыруга тоткарлык ясарга, шулай ук тавыш бирү серен бозарга теләүче участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарылалар. Бу хакта карар участок комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Шул ук вакытта комиссия эштән читләштерелгән участок комиссиясе әгъзасын, шулай ук бинадан чыгарылган күзәтүчене һәм башка затларны федераль законнарда каралган җаваплылыкка тарту турындагы тәкъдим белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

12. Инициатив төркем әгъзаларына һәм вәкаләтле вәкилләргә, шулай ук гамәлгә куючылары, милекчеләре, хуҗалары һәм (яисә) җитәкче органнарының әгъзалары югарыда күрсәтелгән затлар булган оешмаларга, башка физик һәм юридик затларга шушы затларның һәм оешмаларның үтенече яисә кушуы буенча референдумда катнашучыларны тавыш бирүдә катнашу өчен китерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән теләсә нинди гамәлләр кылу тыела.

<u>48 статья.</u> Референдумда катнашучыларның тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү тәртибе

1. Участок комиссиясе шушы референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларга һәм тавыш бирү бинасына мәгълүм сәбәпләр (сәламәтлеге, инвалид булуы һәм башка сәбәпләр) буенча мөстәкыйль рәвештә килә алмаучыларга тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

2. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү бары тик тавыш бирү көнендә генә һәм бары тик референдумда катнашучының тавыш бирү бинасыннан читтә үзенә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы язма гаризасы яисә телдән мөрәҗәгате (шул исәптән башка затлар аша

тапшырылган) нигезендә генә үткәрелә. Гариза (мөрәҗәгать) участок комиссиясе төзелгәннән соң теләсә кайсы вакытта референдумда катнашучы тарафыннан бирелергә мөмкин, әмма ул тавыш бирү вакыты тәмамланырга 4 сәгатьтән дә соң булмаска тиеш. Участок комиссиясе бирелгән барлык гаризаларны (мөрәҗәгатьләрне) махсус реестрда терки.

3. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән реестрда телдән мөрәҗәгатьне теркәгәндә аның керү вакыты күрсәтелә һәм комиссиянең телефонограмманы йә мөрәҗәгатьне тапшырган зат хәбәрен алган әгъзасы имза сала. Комиссия әгъзалары референдумда катнашучы янына килгәч, мөрәҗәгать язма гариза белән раслана.

4. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы гаризада референдумда катнашучының тавыш бирү бинасына килә алмау сәбәбе күрсәтелергә тиеш, шулай ук гаризага референдумда катнашучы турында референдумда катнашучылар исемлегендәге шул ук белешмәләр кертелергә тиеш.

5. Участок комиссиясендә тиешле санда күчерелмә тавыш бирү әрҗәләре булырга тиеш, аларның саны референдумның югарырак комиссиясе карары белән билгеләнә һәм ул өчтән дә артык булмаска тиеш.

6. Участок комиссиясенең гаризалар (мөрәҗәгатьләр) буенча чыгучы әгъзалары, имза салып, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре алалар. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия кимендә ике әгъзасы уздыра, алар үзләре белән участок комиссиясендә алдан мөһерләнгән (пломбаланган) күчерелмә тавыш бирү әрҗәсе, тиешле санда мәгълүм рәвешле референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре, әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән реестрдан референдумда катнашучы турында һәм тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турында кергән гариза (мөрәҗәгать) хакында таныкланган өземтә, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турында референдумда катнашучылардан кергән язма гаризаларны, шулай ук референдумда тавыш бирү бюллетенен референдумда катнашучы тарафыннан тутыру өчен кирәкле язу әйберләре алырга тиешләр.

7. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү әлеге Законның 47 статьясы таләпләре үтәлгән килеш гамәлгә ашырыла.

8. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы язма гаризада референдумда катнашучы үзенең паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясен һәм номерен куя һәм, референдумда тавыш бирү бюллетенен алуын раслап, үзенең имзасын сала. Комиссия әгъзалары гаризада үз имзалары белән референдумда тавыш бирү бюллетенен бирү фактын раслыйлар. Гаризада шулай ук бозылганы урынына яңа бюллетень алу турында да тамга ясала, ә референдумда катнашучы тарафыннан ике яисә аннан күбрәк бюллетень алынган очракта - алынган бюллетеньнәрнең гомуми саны күрсәтелә.

9. Участок комиссиясенең референдумда катнашучыларның гаризалары (мөрәҗәгатьләре) буенча чыккан әгъзалары референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен бары тик гаризалары (мөрәҗәгатьләре) әлеге статьяның 2 пункты нигезендә реестрда теркәлгән референдумда катнашучыларга гына бирергә хокуклы.

10. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучы паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры участок комиссиясенең референдумда катнашучылар гаризалары (мөрәҗәгатьләре) буенча чыккан, хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан референдумда катнашучылар исемлегенә кертелә. Референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) бер үк вакытта «Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирде» дигән махсус тамга куела.

11. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырганда референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр катнашырга хокуклы. Мондый чакта участок комиссиясе референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия кимендә ике әгъзасына, күзәтүчеләргә участок комиссиясенең тавыш бирүне уздыру өчен чыгучы әгъзаларына бирелгән шул ук мөмкинлекләрне тудырырга тиеш. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне оештыру референдумда катнашучының референдумда катнашу хокукын бозу мөмкинлеген, шулай ук референдумда катнашучының ихтыяр белдерүен бозуын булдырмаска тиеш.

12. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеген тудыру турында гариза (мөрәҗәгать) биргән референдумда катнашучы участок

317

комиссиясе бинасына тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздыру өчен аның янына комиссия әгъзаларын җибәргәннән соң тавыш бирергә килгән очракта, участок комиссиясенең тиешле әгъзасы, референдумда әлеге катнашучының гаризасы (мөрәҗәгате) буенча чыккан комиссия әгъзалары кире әйләнеп кайтканчы һәм референдумда шушы катнашучы тарафыннан тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү булмаганлыгы факты билгеләнгәнче, аңа комиссия бинасында тавыш бирү бюллетенен бирергә хокуклы түгел.

13. Референдумда катнашучыларның язма гаризаларының саны, шулай ук референдумда тавыш бирүнең бирелгән, файдаланылган һәм кире кайтарылган бюллетеньнәре саны аерым актта билгеләнә, анда шулай ук участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары һәм тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырганда катнашкан күзәтүчеләр турында да белешмәләр күрсәтелә.

49 статья. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе

1. Участок комиссиясе тиешле референдум участогында тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи.

2. Участок комиссиясе беркетмәсе бер биттә төзелергә тиеш. Аерым очракларда гына беркетмә бердән күбрәк биттә төзелә ала, болай булганда, аның һәр битенә участок комиссиясенең шунда катнашкан хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары имза салырга тиеш. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) нөсхәнең номеры;

б) референдумның исеме, тавыш бирү датасы;

в) «Беркетмә» сүзе;

г) референдум участогының номеры күрсәтелеп, участок комиссиясенең исеме;

д) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: референдумның участок комиссиясе тарафыннан алынган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

3 юл: референдумда тавыш бирүнең тотылган бюллетеньнәре саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә референдум участогында референдумда катнашучыларга бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны (референдумда катнашучылар исемлегендәге референдумда катнашучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юл: тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны (референдумда катнашучылар исемлегендә тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

6 юл: күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

7 юл: стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

8 юл: референдумда тавыш бирүнең гамәлгә яраклы бюллетеньнәре саны;

9 юл: референдумда тавыш бирүнең гамәлгә яраксыз, шул исәптән кайбер юллары буенча гамәлгә яраксыз референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең гомуми саны;

10 юл: референдумда тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләреннән алынган тавыш бирү бюллетеньнәренең саны референдумда катнашучыларның референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен алулары турында тамга куелган гаризалары санынннан артып киткәндә, гамәлгә яраксыз дип танылган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

11 юл: бер позиция буенча да тамгасы булмаган яисә бердән артыграк позициядә тамгалары булган гамәлгә яраксыз референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

12 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

13 юл: референдум участогында тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе тарафыннан референдумда катнашучыларга бирелгән бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юл: референдум участогында бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

15 юл: кулланылмый калып, референдум участогында гамәлдән чыгарылган бүтән референдум участогында тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

16 юл һәм аннан соңгы юллар: референдумда катнашучыларның референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрендәге «әйе» яисә «юк» позициясе өчен бирелгән тавышлары саны:

е) беркетмәгә кушымта итеп бирелүче шикаятьләр (гаризалар), актлар һәм башка документлар исемлеге;

ж) референдум комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретаренең һәм башка әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары, аларның имзалары;

з) беркетмәгә имза салынган дата һәм вакыт (сәгатьләре һәм минутлары, әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен);

и) референдум комиссиясенең мөһере (әгәр беркетмә бер биттән артыграк төзелгән булса - беркетмәнең һәр бите саен);

Референдумга мәсьәлә чишелешенең альтернатив вариантлары чыгарылган очракта, беркетмәгә барлык вариантлар һәм референдумда катнашкан гражданнарның һәр вариант өчен тавыш биргән тавышларының саны, шулай ук референдумда катнашкан гражданнарның барлык вариантларга каршы бирелгән тавышлары саны кертелә.

3. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә цифрлар белән һәм язмача кертелә.

50 статья. Референдумда катнашучыларның тавышларын санау һәм тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре тарафыннан беркетмә төзү тәртибе

1. Референдумда катнашучыларның тавышларын санау участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан ачык-тан-ачык һәм хәбәрдар башкарыла.

320

2. Референдумда катнашучыларның тавышларын санау тавыш бирү вакыты узгач үк башлана һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәнгә кадәр өзлексез уздырыла, участок комиссиясенең барлык әгъзаларына, шулай ук күзәтүчеләргә тавыш бирү йомгаклары турында хәбәр ителергә тиеш.

3. Референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда участок комиссиясе, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәр позициясен билгеләп, аны игълан итә, күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә, беркетмәнең зурайтылган рәвешенә кертә, шуннан соң гына киләсе позицияне билгеләүгә күчә.

4. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затлар катнашында, файдаланылмаган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен санып‌‌йлар, сул яктагы аскы почмагын кисеп яраксызга чыгаралар (бу чакта «әйе» һәм «юк» сүзләре астында урнаштырылган квадратларны, ә референдумга мәсьәләне хәл итүнең альтернатив вариантлары чыгарылган очракта - «барлык вариантларга каршы» дигән квадратларны зарарлау рәхсәт ителми), шуннан соң файдаланылмаган бюллетеньнәр саны игълан ителә һәм алар, шулай ук тавыш биргәндә референдумда катнашучылар бозган бюллетеньнәр саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 3 нче юлына язып куела.

5. Референдумда катнашучыларның тавышларын санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

а) территория һәм участок комиссияләрендә тавыш бирү өчен бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары бирелгән референдумда катнашучыларны исәпкә алмыйча, исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар санын;

б) референдум участогында референдумда катнашучыларга тавыш бирү көнендә бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре санын (референдумда катнашучылар исемлегендәге референдумда катнашучыларның имзалар саны буенча билгеләнә);

в) тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга тавыш бирү өчен бирелгән референдумда тавыш бирү

бюллетеньнәре санын (референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

г) референдумда катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан референдум участогында бирелгән бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары санын;

д) референдум участогында бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән референдумда катнашучылар санын.

6. Әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң референдумда катнашучылар исемлегенең һәр битенә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы имза сала, ул бу күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә участок комиссиясе секретарена һәм тавышларны санауда катнашкан затларга хәбәр итә. Референдумда катнашучылар исемлегенең соңгы битенә участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре әлеге статьяның 5 пункты нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен кертә, аларны имза һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Шуннан соң референдумда катнашучылар исемлеге белән әлеге Законның 27 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар танышырга хокуклы.

7. Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре түбәндәгеләрне төгәлләштерәләр, игълан итәләр һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 1 һәм 2 юлларына кертәләр:

а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын;

б) участок комиссиясе тарафыннан алынган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре санын.

8. Аннары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

12 юлга - участок комиссиясе тарафыннан алынган бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

322

13 юлга - участок комиссиясе тарафыннан референдум участогында референдумда катнашучыларга бирелгән бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары саны;

14 юлга - бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары буенча референдум участогында тавыш биргән референдумда катнашучылар саны;

15 юлга - кулланылмый калып, референдум участогында гамәлдән чыгарылган бүтән референдум участогында тавыш бирү бюллетеньнәре саны;

9. Аннары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

4 юлга - тавыш бирү көнендә референдумда катнашучыларга референдум участогында бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны (референдумда катнашучылар исемлегендәге референдумда катнашучыларның имзалары саны буенча билгеләнә);

5 юлга - тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны (референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә).

10. Бу гамәлләрдән соң референдум комиссиясе рәисе яисә секретаре референдумда катнашучылар исемлеген тавышларны санауда катнашучы затлар ала алмаслык итеп саклауны тәэмин итәргә тиешләр. Референдумда катнашучылар исемлеге белән алга таба эш итү тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә әлеге статьяның 23 пункты нигезендә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары тикшерелгәннән соң гына башкарылырга мөмкин.

11. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирү әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәр буенча референдумда катнашучыларның тавышларын турыдан-туры санауны гамәлгә ашыралар.

12. Тавышларын турыдан-туры санаганда участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында санап үтелгән башка затлар катнаша ала.

13. Референдумда катнашучыларның тавышларын турыдан-туры санау махсус билгеләнгән урыннарда үткәрелә, алар референдум комиссиясенең

хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына да, киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына да кереп йөрү тәэмин ителерлек итеп җиһазланырга тиеш. Референдум комиссиясе рәисеннән (рәис урынбасарыннан) һәм референдум комиссиясе секретарыннан гайре, референдум комиссиясе әгъзаларына тавышларны санаганда язу әсбапларыннан файдалану тыела. Бу вакытта референдум комиссиясе әгъзаларының гамәлләре тавышларны санаганда шунда булучыларның барысы өчен дә тулы күренүе тәэмин ителергә тиеш.

14. Тавыш бирү әрҗәләрен ачарга керешкәнче, участок комиссиясе рәисе тавыш бирү әрҗәләрендәге мөһерләрнең яисә пломбаларның бөтенлеген тикшерә.

15. Референдум комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күчерелмә һәм стационар тавыш бирү әрҗәләреннән алынган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен, «әйе» һәм «юк» позицияләре өчен бирелгән (референдумга мәсьәләне хәл итүнең альтернатив вариантлары чыгарылган очракта — «барлык вариантларга каршы») тавышлар буенча аралыйлар, бер үк вакытта билгеләнмәгән рәвештәге референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре һәм гамәлгә яраксыз референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре аерып куела. Референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен аралаганда, участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары референдумда тавыш бирү бюллетенендә референдумда катнашучы куйган тамгаларны игълан итәләр һәм карап тикшерү өчен аларны тавышларны турыдан-туры санауда катнашучыларның барысына да күрсәтәләр. Бер үк вакытта ике һәм аннан артык референдумда тавыш бирү бюллетене эчтәлеген игълан итү рөхсәт ителми.

16. Башта күчерелмә тавыш бирү әрҗәләрендәге референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре санала. Әрҗәләрдән алынган мәгълүм үрнәктәге бюллетеньнәр саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 6 нчы юлына язып куела. Күчерелмә әрҗәләредәге мәгълүм үрнәктәге референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре санының тавыш бирү бинасыннан читтә бюллетеньнәр алу турында референдумда катнашучыларның гаризаларындагы тамгалар саныннан артып китүе ачыкланган очракта, әлеге күчерелмә тавыш бирү әрҗәсендәге барлык бюллетеньнәр участок комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип танылалар, бу хакта аерым акт төзелә, ул тавыш бирү йомгаклары

турындагы беркетмәгә кушылып бирелә, анда участок комиссиясенең тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне шушы тавыш бирү әрҗәсен файдаланып уздырган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелә. Бу очракта гамәлгә яраксыз дип танылган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре саны референдумда тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 10 нчы юлына кертелә.

17. Аннары участок комиссиясе әгъзалары стационар тавыш бирү әрҗәләрендәге мәгълүм үрнәктәге тавыш бирү бюллетеньнәре санала һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 7 нче юлына язып куела.

18. Шуннан соң участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзлары контрольдә тоткан килеш, референдум комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр аерып куелган тавыш бирү бюллетеньнәрен карап, танышырга хокуклы.

19. Тавышларны санаганда, участок комиссиясе билгеләнмәгән рәвешне референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен, ягъни рәсми әзерләнмәгән йә референдум комиссиясе тарафыннан таныкланмаган бюллетеньнәрне аерып ала. Билгеләнмәгән рәвешле бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

20. Шулай ук референдумда тавыш бирүнең гамәлгә яраксыз бюллетеньнәре дә аерып куела. Референдумда катнашучыларның үз ихтыярларын белдерүләрен тәгәл ачыклап булмый торган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр дип санала, мондыйларга түбәндәгеләр керә: бердән артык позициягә тамга куелган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре; позицияләрнең берсенә дә тамга куелмаган референдумда тавыш бирү бюллетеньнәре. Бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип таныганда шик туган очракта, участок комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә, бу вакытта бюллетеньнең арткы ягында гамәлгә яраксызлыгының сәбәпләре күрсәтелә. Бу язу комиссиянең кимендә өч әгъзасы имзасы белән таныклана һәм комиссия мөһере белән раслана. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең саны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 9 һәм 11 нче юлларына кертелә.

21. Участок комиссиясе әгъзалары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 8 нче юлына референдумда тавыш бирүнең гамәлгә яраклы бюллетеньнәренең санын язып куялар.

325

22. Аннары билгеләнгән рәвешле бюллетеньнәр буенча референдумда катнашучыларның тавышлары санала. Референдум комиссиясенең кимендә ике әгъзасы референдумда тавыш бирүнең «әйе» һәм «юк» позицияләре буенча (референдумга мәсьәләне хәл итүнең альтернатив вариантлары чыгарылган очракта - «барлык вариантларга каршы») бюллетеньнәрен санийлар. Алынган күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 16 нчы юлына һәм аннан соңгы юлларына язып куела.

23. Шуннан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары (2 нче кушымта) тикшерелә. Контроль чагыштырмалар тәңгәл килмәгән очракта, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юлларын кабат санау турында, шул исәптән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен өстәмә санау турында, карар кабул итә. Кабат санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәрешләр кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла.

24. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә өч нөсхәдә тутырыла һәм аларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза салалар, анда имза салу көне һәм вакыты (сәгате, минуты) күрсәтелә.

25. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне тутырганда участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия кайбер әгъзалары булмаса, аларның булмау сәбәпләре күрсәтелеп,беркетмәдә бу хакта язып куела. Беркетмәгә референдумның тиешле комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелеге имза салган булса, беркетмә гамәлгә яраклы була.

26. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми. Участок комиссиясенең беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерләрен кушымта итеп бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

27. Участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча участок комиссиясе, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә имзалар салынгач, кичекмәстән әлеге затларга күчермәсен бирергә яисә тавыш бирү йомгакла-

326

ры турындагы беркетмәнең күчермәсен әзерләргә мөмкинлек бирергә, шулай ук аны таныкларга тиеш.

28. Участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсенең беренче нөсхәсе, аңа участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашкан барлык әгъзалары имза салгач, кичекмәстән территория комиссиясенә җибәрелә һәм участок комиссиясенә кире кайтарылмый. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, участок комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар), шулай ук референдум комиссиясенең күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлары һәм участок комиссиясе төзегән актлар теркәлеп куела. Әлеге документларның таныкланган күчермәләре һәм референдум комиссиясенең карарлары беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлеп куела.

29. Беркетмәнең икенче нөсхәсе, референдум әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле документлар белән бергә, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санаганда участок комиссиясенең шунда булган киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, чит ил (халыкара) күзәтүчеләренең, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең исемлеген дә кертеп, шулай ук участок комиссиясенең мөһере, пломба салып мөһерләнгән килеш, участок комиссиясенең эше тәмамлаганчы, саклануы бинада участок комиссиясе секретаре тарафыннан саклана.

30. Беркетмәнең өченче нөсхәсе (аның күчермәсе) участок комиссиясе тарафыннан билгеләнгән урында гомуми танышу өчен эленеп куела.

31. Референдумда тавыш биргәндә участок комиссияләре тавышларны санауның техник чараларыннан, шул исәптән референдумда тавыш бирү бюллетеньнәренең сканерларыннан файдаланырга хокуклы. Күрсәтелгән техник чаралар ярдәмендә алынган тавыш бирү йомгаклары юридик көчкә ия булмаган якынча мәгълүмат кына була.

32. Тавышларны санау өчен техник чаралардан файдаланганда, референдум участогында тавыш бирү тәмамланганчы, тавышларны санау күрсәткечләрен, тавыш биргән референдумда катнашучыларның гомуми саны турындагы күрсәткечләрдән гайре, хәбәр итү тыела.

327

33. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә күрсәткечләре техник элемтә каналлары буенча электрон рәвештә (дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы йә бүтән техник система кысаларында) референдумның югарырак комиссиясенә тапшырыла, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсе, шулай ук, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен дә кертеп, референдумның барлык документлары референдумның югарырак комиссиясенә мөмкинлек булу белән үк турыдан-туры, йә референдум документларының сакланышын һәм аның кирәк урынга җиткерелүен тәэмин итәрлек бүтән ысул белән илтеп җиткерелә.

34. Референдум үткәрү турындагы мәгълүматны тапшыруның техник системасыннан файдалану тәртибе, күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру, эшкәртү һәм файдалану тәртибе һәм вакытлары,шул исәптән тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең электрон рәвештә техник элемтә каналлары буенча тапшырылган күрсәткечләре Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

35. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салынганнан һәм аның беренче нөсхәсе территория комиссиясенә җибәрелгәннән соң беркетмә төзегән участок комиссиясе анда төгәлсезлек (күрсәткечне ялгыш язу, хәреф хатасы яисә күрсәткечләрне кушкандагы ялгыш) барлыгын ачса, ул үзенең утырышында беркетмәгә аныклаулар кертү турындагы мәсьәләне карарга тиеш. Участок комиссиясе әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затларга шушы утырышның үткәрелүе турында хәбәр итеп, анда әлеге мәсьәләнең каралачагын күрсәтергә тиеш. Кабул ителгән карар турында участок комиссиясе мәҗбүри рәвештә үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм тавыш бирү йомгаклары турында элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә хәбәр итә. Бу очракта участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Кабатланганы» дигән тамга сала. Әлеге беркетмә кичекмәстән территория комиссиясенә җибәрелә. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең территория комиссиясенә элек тапшырган беркетмәсе кабат язылган беркетмәгә кушып бирелә.

51 статья. Территория комиссияләрендә тавыш бирү йомгакларын эшкәртү

1. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләренең беренче беркетмәләре күрсәткечләре нигезендә территория комиссиясе, алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән аларның дөрес төзелүен алдан тикшергәннән соң, тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгели. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләренең беркетмәләрендәге күрсәткечләрне кушып берләштерүне территория комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үзләре башкаралар.

2. Тавыш бирү йомгаклары буенча территория комиссиясе беркетмә төзи, аңарга тиешле территориядәге участок комиссияләренең саны турындагы һәм участок комиссияләреннән кергән беркетмәләр саны турындагы күрсәткечләр (шуларга нигезләнеп, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзелә), шулай ук участок комиссияләре беркетмәләренең әлеге Законның 49 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән юллар буенча кушып берләштерелгән күрсәткечләр кертелә.

3. Территория комиссиясе беркетмәсе өч нөсхәдә төзелә һәм аларга территория комиссиясенең шунда катнашкан хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары имза сала. Беркетмәләргә тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында өч нөсхәдә җыелма таблица (бу таблица тавыш бирү йомгаклары турында барлык участок комиссияләреннән кергән беркетмәләрнең тулы күрсәткечләрен үз эченә ала), шулай ук тавыш бирү бюллетеньнәрен территория комиссияләренең алулары турында, аларны участок комиссияләренә тапшырулары турында, территория комиссиясендә сакланган, тотылмаган тавыш бирү бюллетеньнәрен гамәлдән чыгару турында, (мондый бюллетеньнәрнең саны күрсәтелгән килеш) бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын участок комиссияләренә тапшыру турында, актлар беркетелеп бирелә.

4. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә территория комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук территория комиссиясенә кертелгән шикаятьләр (гаризалар) һәм алар буенча референдум комиссиясенең кабул ителгән карарлары кушып куела. Аерым фикерләрнең, шика-

329

ятьләрнең (гаризаларның) һәм территория комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә өстәп куела.

5. Тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе имза салынганнан соң, җыелма таблицаның беренче нөсхәсе белән бергә, кичекмәстән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

6. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе һәм җыелма таблицаның икенче нөсхәсе, референдум комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия һәм беркетмә төзегән әгъзаларының, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмәләр төзегәндә шунда булган күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затларның исемлекләре белән бергә, шулай ук әлеге Законда каралган бүтән документлар комиссия эше тәмамланганчы, сакланылучы бинада территория комиссиясе тарафыннан саклананалар.

7. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең әченче нөсхәсе һәм җыелма таблицаның өченче нөсхәсе танышу һәм күчермәләрен алу өчен территория комиссиясе әгъзаларына һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бүтән затларга бирелә.

8. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага имза салынганнан һәм аларның беренче нөсхәләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелгәннән соң, территория комиссиясе аларда төгәлсезлекләр (участок комиссияләре беркетмәләренең күрсәткечләрен кушканда төшеп калу, хәреф хатасы йә ялгыш җибәрү) ачыклаган очракта, ул беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне үзенең утырышында карарга хокуклы. Кабул ителгән карар турында территория комиссиясе үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга,шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта территория комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Кабатланганы» дигән тамга сала. Әлеге беркетмә кичекмәстән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

9. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләреннән кергән беркетмәләрдә һәм (яисә) җыелма таблицаларда хаталар, ярашмаулар ачыкланганда яисә участок комиссияләреннән кергән беркетмәләрнең һәм (яисә) җыелма таблицаларның төзелү дөреслегенә шик туганда, территория комиссиясе референдумда катнашучыларның тавышларын участок комиссиясе тарафыннан кабат санау уздыру турында йә тиешле референдум участогында референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санауны мөстәкыйль уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы. Референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санау территория комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында уздырыла. Референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санауны уздыручы территория комиссиясе бу хакта участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затларга хәбәр итә. Референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча мондый санауны башкарган участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга сала. Беркетмә кичекмәстән югарырак референдум комиссиясенә җибәрелә.

<u>52 статья.</u> Референдум нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе

1. Тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссияләреннән кергән беркетмәләрнең беренче нөсхәләре нигезендә алардагы күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, референдум уздырылганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча, референдум нәтиҗәләрен билгели. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары референдум нәтиҗәләрен шәхсән үзләре билгелиләр.

2. Референдум нәтиҗәләре турында өч нөсхәдә беркетмә һәм җыелма таблица төзелә, аларга Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашкан барлык әгъзалары имза сала. Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

331

а) Татарстан Республикасы территориясендәге территория комиссияләренең саны;

б) тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссияләре беркетмәләренең саны;

в) тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссияләре беркетмәләрендәге барлык юллар буенча суммар күрсәткечләр.

3. Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның яртысыннан кимрәге (референдумда катнашкан референдумда катнашучыларның саны тавыш бирү бюллетеньнәре алган референдумда катнашучылар саны буенча билгеләнә) катнашса, референдум узмаган дип таныла. Әгәр тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның (тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны тавыш бирү әрҗәләреннән алынган референдумда тавыш бирүнең билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәре саны буенча билгеләнә) яртыдан кимрәге референдумда куелган мәсьәлә өчен тавыш бирсә, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе бу карарны кабул ителмәгән дип таный. Әгәр референдумга мәсьәләнең альтернатив вариантлары чыгарылган булса һәм күрсәтелгән вариантларның берсе дә тавышларның кирәкле санын җыймаса, барлык вариантлар да кабул ителмәгән дип санала.

4. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе референдум нәтиҗәләрен түбәндәге очракларда дөрес түгел дип таный:

а) тавышлар бирүне үткәргәндә яисә тавыш бирүнең йомгакларын билгеләгәндә җибәрелгән хокук бозулар референдумда катнашучыларның ихтыярларын белдерү нәтиҗәләренең дөреслеген билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта;

б) референдум участокларының кимендә дүрттән берендә алар дөрес түгел дип танылган очракта;

в) суд карары буенча.

5. Референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә имзалар салынгач, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе танышу

332

һәм күчермәләр алу өчен беркетмә һәм җыелма таблица күчермәләрен бирергә тиешләр.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең референдум нәтиҗәләре турындагы беркетмә белән тулысынча яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәүче хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үзенең аерым фикерен кушып бирергә хокуклы, бу хакта беркетмәдә тиешенчә язып куела.

7. Референдум нәтиҗәләре турында беркетмәне һәм (яисә) җыелма таблицаны имзалаганнан соң, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе аларда төгәлсезлек (шул исәптән төшеп калу, хәреф хатасы йә түбәнгерәк референдум комиссияләренең беркетмәләрендәге белешмәләрне кушканда хата җибәрелү) ачыкласа, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе үзенең утырышында беркетмәгә һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү хакындагы мәсьәләне карарга тиеш. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пункты нигезендә утырыш үткәрү турында хәбәр итеп, анда әлеге мәсьәләнең каралачагын күрсәтергә тиеш. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе үзе кабул иткән карар турында үзенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына, элек расланган беркетмәне төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итәргә тиеш.

8. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә һәм (яисә) җыелма таблицаларда хаталар, ярашмаулар ачыкланганда яисә территория комиссияләреннән кергән беркетмәләрне һәм (яисә) җыелма таблицаларны төзүнең дөреслегенә шик туганда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тиешле территориядә референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санауны үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

9. Референдумда катаншучыларның тавышларын кабат санау Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) катнашында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне төзүче һәм раслаучы референдум комиссиясе, йә югарырак референдум комиссиясе, йә Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан үткәрелергә һәм бу беркетмә тикшерелергә тиеш. Референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санауны

333

үткәрүче комиссия бу хакта тиешле референдум комиссиясе әгъзаларына, референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санауны үткәргәндә катнашырга хокукы булган, әлеге Законның 27 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән башка затларга хәбәр итә. Референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча мондый санауны үткәрүче комиссия тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дигән тамга сала. Тавыш бирү йомгаклары турында элек тәкъдим ителгән беркетмә референдумда катнашучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча төзелгән беркетмәгә кушып бирелә.

10. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе референдум нәтиҗәләре турындагы гомуми күрсәткечләрне референдум нәтиҗәләре мәгълүм булганнан соң бер тәүлек эчендә массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрә.

<u>53 статья.</u> Тавыш бирү йомгакларын һәм референдум нәтиҗәләрен бастырып чыгару

1. Һәр референдум участогы, комиссия эшчәнлеге җәелдерелгән һәр территория буенча тавыш бирү йомгаклары, референдум нәтиҗәләре Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе,референдум комиссияләре беркетмәсендәге күрсәткечләр күләмендә референдумда катнашучыларга, инициатив төркем әгъзаларына һәм вәкилләренә, күзәтүчеләргә, чит ил (халыкара) күзәтүчеләренә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә аларның таләпләре буенча танышу өчен бирелә. Мондый күрсәткечләр бирүне референдумның тиешле комиссиясе башкара.

2. Референдум нәтиҗәләре,шулай ук «әйе» һәм «юк» позицияләре өчен референдумда катнашучыларның бирелгән тавышлары саны турындагы күрсәткечләр, тавыш бирелгән көннән соң бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан рәсми бастырып чыгарыла.

3. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, территория комиссияләре тавыш бирү йомгаклары һәм референдум нәтиҗәләре турындагы әлеге комиссия беркетмәсендә булган күрсәткечләрне һәм тавыш

334

бирү йомгаклары турында референдумның түбәнгерәк комиссиясенең беркетмәләрендә булган күрсәткечләрне (шулар нигезендә референдум нәтиҗәләре билгеләнә) бастырып чыгаралар. Референдум нәтиҗәләре турында тулы күрсәткечләр тавыш бирелгән көннән соң ике ай эчендә рәсми бастырып чыгарыла.

54 статья. Референдумда кабул ителгән карарның юридик көче

1. Референдумда кабул ителгән карар гомуммәҗбүри була һәм өстәмә рәвештә раслану мохтаҗ түгел, әгәр референдумда кабул ителгән карарда башкасы каралмаган булса, ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

2. Референдумда кабул ителгән карар Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлдә була.

3. Референдумда кабул ителгән карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларны теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында теркәлә.

4. Референдумда кабул ителгән карар референдумда бүтән карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яисә үзгәртелергә мөмкин, әмма бу хәл ул кабул ителгәннән соң ике елдан да алданрак була алмый йә суд тәртибендә гамәлгә яраксыз дип танылганда гына мәмкин була.

5. Референдумда кабул ителгән карарны суд тарафыннан юкка чыгару түбәндәге нигезләр буенча башкарылырга мөмкин:

референдум уздыруның әлеге Законда билгеләнгән тәртибен референдумда катнашучыларның ихтыярын белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек тудырмаслык итеп бозганда;

референдумда кабул ителгән карар Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законга, федераль законга, шулай ук Татарстан Республикасы законына каршы килгәндә.

6. Референдумда кабул ителгән карарны тормышка ашыру әчен өстәмә норматив хокукый акт чыгару таләп ителгәндә, дәүләт хакимиятенең әлеге мәсьәлә үз компетенциясенә кертелгән органы референдумда кабул ителгән карар үз кәченә кергән көннән 15 кән эчендә әлеге норматив хокукый актны әзерләү вакытын билгеләргә тиеш.

335

7. Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагында булган мәсьәлә буенча референдум уздырганнан соң шул мәсьәлә буенча федераль закон чыгарылган очракта, референдумда кабул ителгән карар һәм әлеге федераль законга туры килми торган карар кулланылмый.

55 статья. Референдум үткәргәндә дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдалану

1. Референдум үткәргәндә дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы файдаланылырга мөмкин.

2. Референдум үткәргәндә, шул исәптән референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), референдумда катнашучыларның исемлеген төзегәндә, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм референдум нәтиҗәләрен ачыклаганда, дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан тулаем яисә аның аерым техник чараларыннан файдаланганда, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе, тиешле референдум комиссиясе дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (аның аерым техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен комиссиянең хәлиткеч тавыш һәм киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларыннан төркемнәр төзиләр. Комиссиянең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертелүче теләсә нинди мәгълүмат белән танышырга хокуклы.

3. Тавыш бирү башлану мизгеленнән тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә тиешле референдум комиссиясе тарафыннан имза салынган мизгелгә кадәр референдумның түбәнгерәк комиссияләреннән югарырак комиссияләренә күрсәткечләр тапшыру юлы белән тавыш бирүнең барышын һәм тавыш бирү йомгакларын күзәтеп тору өчен дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланыла. Тавыш бирүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша алынган күрсәткечләр юридик әһәмияткә ия булмаган якынча мәгълүмат кына була.

336

4. Референдум барышында дәүләтнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланган очракта, тавыш бирүдә катнашучылар турындагы тавыш бирүнең алданрак бирелгән һәм иң соңгы йомгаклары турындагы күрсәткечләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-коммуникация челтәре абонентлары өчен оператив файдаланырлык («бары тик уку» режимында) булырга тиеш.

56 статья. Референдум документларын саклау

1. Участок комиссияләренең документлары, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен дә кертеп, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча тиешле территория комиссияләренә тапшырыла.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, барлык дәрәҗәләрдәге референдум комиссияләренең документлары, референдумда тавыш бирү бюллетеньнәрен дә кертеп, бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары һәм референдумда катнашучылар исемлекләре - тавыш бирү йомгаклары һәм референдум нәтиҗәләре басылып чыккан көннән бер ел буена, ә тавыш бирү йомгаклары турында күрсәтелгән комиссияләрнең беркетмәләре һәм җыелма таблицалары референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән 5 ел буена сакланырга тиеш.

3. Референдумга әзерләнүгә һәм аны үткәрүгә бәйле документларны саклау һәм архивка тапшыру тәртибе, тиешле дәүләт архив органнары белән килештереп, Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

337

## VIII бүлек. Референдум комиссиясенең карарын юкка чыгару нигезләре һәм референдумда катнашу хокукый бозган әчен җаваплылык

57 статья. Тавыш бирү йомгаклары турында, референдум нәтиҗәләре турында референдум комиссиясе карарын юкка чыгару нигезләре

1. Референдумда катнашучылар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен, референдум комиссияләре төзү тәртибен бозган, үгетләү кагыйдәләрен һәм референдумга әзерләнүне һәм аны үткәрүне финанслау кагыйдәләрен бозган, инициатив төркем әгъзалары, аларның ышанычлы затлары, иҗтимагый берләшмәләрнең җитәкчеләре референдум соравына үзләре теләгәнчә җавап алу ихтыяҗларында үзләренең вазыйфаи урыннарыннан файдаланган, шул ук максатларда әлеге затлар һәм иҗтимагый оешмалар референдумда катнашучыларны сатып алу фактлары билгеләнгән, тавыш бирү һәм тавышларны санау тәртибен бозган (аларны уздыруны күзәтеп торуга тоткарлык тудыруны да кертеп), референдум турындагы законнарны башкача бозган өчен, әгәр бу гамәлләр (гамәл кылмаулар) референдумда катнашучыларның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәсәләр, суд тавыш бирү йомгаклары турында, референдум нәтиҗәләре турында референдум комиссиясе карарын юкка чыгарырга мөмкин.

2. Суд, тавыш бирү йомгаклары турында, референдум нәтиҗәләре турында референдум комиссиясенең карарын Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе референдум үткәрүне регламентлаштыручы федераль законнарда каралган очракларда юкка чыгарырга мөмкин.

3. Участокларның дүрттән береннән күбрәгендә тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләренең карарларын юкка чыгару референдумны дөрес түгел дип тануга китерә.

58 статья. Референдум комиссиясенең карарын юкка чыгару нигезләре һөм референдумда катнашу хокукын бозган өчен җаваплылык

1. Гражданның референдумда катнашу хокукын, референдум турындагы законнарны бозучы затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

2. Референдумда кабул ителгән карарларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

338

## IX бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

59 статья. Әлеге Законның үз көченә керүе

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законын, аннан соңгы үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы,1992, №3; Советская Татария, 1992, 26 февраль, № 39) һәм «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары (Советская Татария, 1991,17 декабрь, № 251) әлеге Закон үз көченә кергән көненнән үз көчләрен югалткан, дип танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1142